та-схемасын («Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Көек-Ерыкса авыл җирлеге «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Югары Ушма, Дүсмәт, Түбән Ушма, Түбән Шүләңгер, Отарка, Шәдче авыл җирлекләре, Алабуга муниципаль районы һәм Удмурт Республикасы белән чиктәш.

## Мамадыш муниципаль районының «Көек-Ерыкса авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чиге

Көек-Ерыкса авыл җирлеге чиге Дүсмәт авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Дүсмәт, Көек-Ерыкса һәм Шәдче авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Комазан авылыннан 1,0 км төньяк-көнбатышта урнашкан 69 нчы тоташу ноктасыннан алып көньякка таба 2,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырларны, Комазан елгасын һәм аның текә ярларын кисеп үтеп, 200 м карьер буенча уза, аннары «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 27 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 250 м төньяк-көнбатышка таба, төньяк чиге буйлап 500 м көнбатышка таба, төньяк-көнбатыш чиге буйлап 900 м көньяк-көнбатышка таба, көньяк-көнбатыш чиге буйлап 500 м көньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң 1,2 км көньяк-көнбатышка таба 41 нче, 40 нчы урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Мамадыш – Кукмара автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп уза, аннары 600 м көньякка таба бу урманчылыктагы 39 нчы урман кварталының көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 100 м бу урманчылыктагы 38 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 1,3 км, сынык сызык ясап, 38 нче урман кварталының төньяк чиге буйлап, 1,3 км, сынык сызык ясап, бу урманчылыктагы 37 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап Югары Ушма, Дүсмәт һәм Көек-Ерыкса авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Иске Комазан авылыннан 1,5 км көньяк-көнбатышта урнашкан 23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Көек-Ерыкса авыл җирлеге чиге Шәдче авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 69 нчы тоташу ноктасыннан алып «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 11 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 700 м көнчыгышка таба, төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 2,0 км төньяк-көнбатышка таба, төньяк чиге буйлап 150 м көнбатышка таба уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 1,9 км төньяк-көнбатышка таба бу урманчылыктагы 3 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 900 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 4,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Мамадыш – Кукмара» – Келәүш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, Көек-Ерыкса, Түбән Шүләңгер һәм Шәдче авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Каргалы авылыннан 603 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 19 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Көек-Ерыкса авыл җирлеге чиге Түбән Шүләңгер авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 19 нчы тоташу ноктасыннан алып Шыя елгасы агымы буенча аска таба 1,2 км уза, шуннан соң 450 м көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Келәүш участок урманчылыгындагы 3В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м көньякка таба, 350 м көньяк-көнчыгышка таба уза, 50 м бу урманчылыктагы 4 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешне һәм яр буендагы агачлык-куаклык массивын ике мәртәбә кисеп үтеп уза, шуннан соң 150 м инеш агымы буенча аска таба Шыя елгасы ермагына кадәр бара, аннары аның агымы буенча аска таба 800 м уза, шуннан соң 100 м көньяк-көнчыгышка таба бу урманчылыктагы 1В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м агачлык-куаклык массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 1В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 200 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 200 м төньяк-көнчыгышка таба уза, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м сазлыкның төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агачлык-куаклык массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 1В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре

буйлап 300 м төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 1,3 км төньякка таба уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 1,6 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м карьер буенча, 1,1 км бу урманчылыктагы 106 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 2,6 км төньяк-көнбатышка таба 106 нчы, 105 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, бу урманчылыктагы 104 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м төньяк-көнбатышка таба һәм 400 м көнчыгышка таба Көек-Ерыкса, Түбән Шүләңгер авыл җирлекләре һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Яңа Чиркәс авылыннан 3,2 км төньяк-көнбатышта «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Keләүш участок урманчылыгындагы 104 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш почмагында урнашкан 20 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Көек-Ерыкса авыл җирлеге чиге Удмурт Республикасы белән чиктәш җирдә 20 нче тоташу ноктасыннан алып Татарстан Республикасы административ чиге буйлап Көек-Ерыкса авыл җирлеге, Алабуга муниципаль районы һәм Удмурт Республикасы чикләре тоташкан урында Яңа Чиркәс авылыннан 2,1 км төньяк-көнбатышта урнашкан 74 нче (16 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

Көек-Ерыкса авыл җирлеге чиге Алабуга муниципаль районы белән чиктәш җирдә 74 нче (16 нчы) тоташу ноктасыннан алып Мамадыш муниципаль районы чиге буйлап Көек-Ерыкса, Отарка авыл җирлекләре һәм Алабуга муниципаль районы чикләре тоташкан урында Мамадыш шәһәренең төньяк чигеннән 3,2 км көнчыгышта урнашкан 38 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Көек-Ерыкса авыл җирлеге чиге Отарка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Көек-Ерыкса һәм Отарка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яковка авылыннан 5,3 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 37 нче тоташу ноктасыннан алып 650 м төньяк-көнчыгышка таба Нократ елгасы акваториясе буенча уза, шуннан соң 150 м көнчыгышка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 33В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап, инешне кисеп үтеп, 1,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 33В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап, сазлыкны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м сазлык буенча, 600 м бу урманчылыктагы 32В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап Анзирка елгасына

кадәр, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 38 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Көек-Ерыкса авыл җирлеге чиге «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге Көек-Ерыкса һәм Түбән Ушма авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Красная Горка авылыннан 3,3 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 36 нчы тоташу ноктасыннан алып 50 м төньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 51В урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 800 м көньяк-көнчыгышка таба һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 150 м төньяк-көнчыгышка таба, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба Нократ елгасы ермагы буенча 150 м, күлнең көньяк-көнбатыш яры буенча 300 м уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба күл буйлап 150 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м уза, Нократ елгасы акваториясе буенча 300 м бара, шуннан соң 500 м исемсез утрауның төньяк-көнчыгыш яры буйлап 37 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Көек-Ерыкса авыл җирлеге чиге Түбән Ушма авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Югары Ушма, Көек-Ерыкса һәм Түбән Ушма авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Хафиз авылыннан 1,7 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 35 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 2,9 км «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 52 нче, 47 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, инешне кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,0 км бу урманчылыктагы 47 нче, 48 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап кибеп баручы инешне кисеп үтеп уза, аннары 350 м көньяк-көнчыгышка таба 48 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң 1,7 км көньяк-көнбатышка таба бу урманчылыктагы 49 нчы, 53 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап сынык сызык ясап уза, аннары 2,1 км көньяк-көнчыгышка таба 53 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м, сынык сызык ясап, 53 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,7 км көньяк-көнчыгышка таба, 500 м көньякка таба уза, аннары 50 м

көньяк-көнчыгышка таба чокыр төбе буенча бара, шуннан соң 800 м кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба ул инешкә койган урынга кадәр уза, 900 м бу инешнең агымы буенча аска таба икенче инеш белән кушылган җиргә кадәр бара, 350 м аның агымы буенча өскә таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 700 м көнчыгышка таба, инешнең текә ярын һәм чокырны кисеп үтеп, 350 м төньяк-көнчыгышка таба бара, 500 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,0 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Мамадыш – Кукмара автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп уза, шуннан соң 400 м көньяк-көнчыгышка таба, төньяк-көнчыгышка таба 150 м бу урманчылыктагы 50В урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 500 м көньяк-көнчыгышка таба 50В урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 300 м көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 50В урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 150 м көнчыгышка таба уза, шуннан соң 150 м төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 50В урман кварталының көньяк чиге буйлап чокырны кисеп үтеп бара, аннары 100 м көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 1,0 км бу урманчылыктагы 50В, 51В урман кварталларының көньяк һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 36 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.

Көек-Ерыкса авыл җирлеге чиге Югары Ушма авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 23 нче тоташу ноктасыннан алып 5,9 км көньякка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 37, 46, 52 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң 1,0 км көнчыгышка таба 52 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 35 нче тоташу ноктасына кадәр бара.»;

10) 15 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

11) 16 нчы кушымтаның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кече Кирмән авыл җирлеге чиге Яке авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Кече Кирмән, Түбән Сон һәм Яке авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Түбән Яке авылыннан 1,5 км төньяк-көнбатышта урнашкан 44 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-

көнчыгышка таба 850 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман массивын кисеп үтеп, 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Омар елгасын кисеп үтеп, 1,0 км «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Норма участок урманчылыгындагы 86 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап сынык сызык ясап уза, аннары бу урманчылыктагы 76 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м төньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м төньяк-көнбатышка таба, 50 м төньяк-көнчыгышка таба, 76 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 400 м уза, аннары 50 м төньяк-көнбатышка таба профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,6 км бу урманчылыктагы 75 нче, 73 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап кибеп баручы инешне кисеп үтеп бара, шуннан соң 700 м төньякка таба 73 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары бу урманчылыктагы 72 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 800 м төньяк-көнбатышка таба, көнбатыш чиге буйлап 250 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 800 м төньякка таба бара, шуннан соң 2,1 км төньяк-көнчыгышка таба, 72 нче, 70 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап сынык сызык ясап уза, аннары 1,3 км көньяк-көнчыгышка таба бу урманчылыктагы 70 нче, 71 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң 1,1 км көньякка таба 71 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 600 м көньяк-көнчыгышка таба бу урманчылыктагы 74 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 43 нче тоташу ноктасына кадәр бара.»;

12) 17 нче кушымтада:

а) икенче абзацта «Малмыж» сүзен «Көек-Ерыкса» сүзенә алмаштырырга;

б) дүртенче абзацта «Малмыж» сүзен «Көек-Ерыкса» сүзенә алмаштырырга;

в) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Түбән Ушма авыл җирлеге чиге Көек-Ерыкса авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 35 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 2,9 км «Мамадыш урманчы-

лыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 52 нче, 47 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, инешне кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,0 км бу урманчылыктагы 47 нче, 48 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап кибеп баручы инешне кисеп үтеп уза, аннары 350 м көньяк-көнчыгышка таба 48 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң 1,7 км көньяк-көнбатышка таба бу урманчылыктагы 49 нчы, 53 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап сынык сызык ясап уза, аннары 2,1 км көньяк-көнчыгышка таба 53 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м, сынык сызык ясап, 53 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,7 км көньяк-көнчыгышка таба, 500 м көньякка таба уза, аннары 50 м көньяк-көнчыгышка таба чокыр төбе буенча бара, шуннан соң 800 м кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба ул инешкә койган урынга кадәр уза, 900 м бу инешнең агымы буенча аска таба икенче инеш белән кушылган җиргә кадәр бара, 350 м аның агымы буенча өскә таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 700 м көнчыгышка таба, инешнең текә ярын һәм чокырны кисеп үтеп, 350 м төньяк-көнчыгышка таба бара, 500 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,0 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Мамадыш – Кукмара автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп уза, шуннан соң 400 м көньяк-көнчыгышка таба, төньяк-көнчыгышка таба 150 м бу урманчылыктагы 50В урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 500 м көньяк-көнчыгышка таба 50В урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 300 м көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 50В урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 150 м көнчыгышка таба уза, шуннан соң 150 м төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 50В урман кварталының көньяк чиге буйлап чокырны кисеп үтеп бара, аннары 100 м көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 1,0 км бу урманчылыктагы 50В, 51В урман кварталларының көньяк һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап

«Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Көек-Ерыкса һәм Түбән Ушма авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яковка авылыннан 4,4 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 36 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.»;

г) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Түбән Ушма авыл җирлеге чиге Красная Горка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Красная Горка, Түбән Ушма һәм Урта Кирмән авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Түбән Ушма авылыннан 3,0 км көньяк-көнбатышта урнашкан 40 нчы тоташу ноктасыннан алып көнчыгышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, 600 м урман полосасы буйлап, 1,4 км урман полосасының көньяк чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,0 км урман полосасының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,5 км төньяк-көнчыгышка таба, Мамадыш – Теләче автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 750 м көньяк-көнчыгышка таба, 150 м төньяк-көнчыгышка таба, «Мамадыш – Теләче» – Түбән Ушма автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары 800 м көньяк-көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап урман массивын кисеп үтеп уза, шуннан соң 50 м кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба, 4,0 км Ушма елгасы агымы буенча аска таба бара, аннары төньякка таба 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман утыртмаларының көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,1 км төньякка таба, 1,3 км көньяк-көнчыгышка таба кибеп баручы инешкә кадәр, чокырны һәм текә ярны кисеп үтеп, 39 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.»;

13) 18 нче кушымтада:

а) икенче абзацта «Дегетле,» сүзен төшереп калдырырга;

б) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Түбән Сон авыл җирлеге чиге Яке авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 44 нче тоташу ноктасыннан алып көньякка таба 300 м «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Усали участок урманчылыгындагы 43 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,4 км бу урманчылыктагы 43, 47, 48 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 1,3 км көньяк-көнчыгышка таба бу урманчылыктагы 48 нче, 50 нче ур-

ман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 50 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 150 м көньякка таба, көньяк чиге буйлап 1,5 км көнбатышка таба, көньяк-көнбатыш чиге буйлап 800 м төньяк-көнбатышка таба Дегетле елгасын кисеп үтеп уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 1,3 км бу урманчылыктагы 49 нчы, 52 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,8 км бу урманчылыктагы 52 нче, 54 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап кибеп баручы инешне кисеп үтеп бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 1,9 км бу урманчылыктагы 59 нчы, 62 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 1,2 км бу урманчылыктагы 62 нче, 64 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап бара, аннары 400 м көнбатышка таба 64 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң 1,0 км көньякка таба, сынык сызык ясап, бу урманчылыктагы 67 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап Түбән Сон, Урманчы һәм Яке авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Дегетле авылыннан 3,1 км көньяк-көнбатышта урнашкан 51 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

в) сигезенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

14) 20 нче кушымтаның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Түбән Шүләңгер авыл җирлеге чиге Көек-Ерыкса авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Көек-Ерыкса, Түбән Шүләңгер һәм Шәдче авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Каргалы авылыннан 603 м төньяк-көнчыгышта урнашкан 19 нчы тоташу ноктасыннан алып Шыя елгасы агымы буенча аска таба 1,2 км уза, шуннан соң 450 м көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Келәүш участок урманчылыгындагы 3В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 400 м көньякка таба, 350 м көньяк-көнчыгышка таба уза, 50 м бу урманчылыктагы 4 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап инешне һәм яр буендагы агачлык-куаклык массивын ике мәртәбә кисеп үтеп уза, шуннан соң 150 м инеш агымы буенча аска таба Шыя елгасы ермагына кадәр бара, аннары аның агымы буенча аска таба 800 м уза, шуннан соң 100 м көньяк-көнчыгышка таба бу урманчылыктагы 1В ур-

ман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м агачлык-куаклык массивының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, 1В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап 200 м көньяк-көнчыгышка таба һәм 200 м төньяк-көнчыгышка таба уза, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м сазлыкның төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м агачлык-куаклык массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м 1В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 1,3 км төньякка таба уза, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 1,6 км урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м карьер буенча, 1,1 км бу урманчылыктагы 106 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 2,6 км төньяк-көнбатышка таба 106 нчы, 105 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, бу урманчылыктагы 104 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 200 м төньяк-көнбатышка таба һәм 400 м көнчыгышка таба 20 нче тоташу ноктасына кадәр бара.»;

15) 23 кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мамадыш муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм
аның составындагы муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре
чикләрен билгеләү
һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
23 нче кушымта

**Мамадыш муниципаль районының «Омар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Омар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Мамадыш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Омар авыл җирлеге Красная Горка, Отарка, Соколка, Уразбахты, Яке авыл җирлекләре, Түбән Кама һәм Чистай муниципаль районнары белән чиктәш.

## Мамадыш муниципаль районының «Омар авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чиге

Омар авыл җирлеге чиге Яке авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Омар, Яке авыл җирлекләре һәм Чистай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 439751,74, Y = 2238510,36 координаталы 67 нче тоташу ноктасыннан алып 1,4 км төньяк-көнбатышка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча уза, шуннан соң 950 м көнбатышка таба бу сусаклагычның уң яры буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сазлыкны һәм агачлык-куаклык массивын кисеп үтеп, 100 м агачлык-куаклык массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,1 км «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бөрсет участок урманчылыгындагы 55 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң 4,2 км Заборный елгасы агымы буенча өскә таба бара, аннары 4,3 км инеш агымы буенча өскә таба уза, шуннан соң 350 м төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м инеш агымы буенча өскә таба аңа кибеп баручы инеш койган урынга кадәр бара, 2,1 км кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м бу урманчылыктагы 71 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, шуннан соң 1,5 км кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба ул икенче кибеп баручы инеш белән кушылган урынга кадәр уза, аннары 1,3 км кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба бара, шуннан соң 1,4 км көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 650 м кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба бара, шуннан соң 1,2 км инеш агымы буенча аска таба уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Омар, Уразбахты һәм Яке авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Уразбахты авылын-

нан 3,5 км көньяк-көнбатышта урнашкан 54 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Омар авыл җирлеге чиге Уразбахты авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 54 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,1 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап чокырны һәм инешнең текә ярын кисеп үтеп уза, 2,7 км бу инеш агымы буенча аска таба бара, аннары 4,4 км Омар елгасы агымы буенча өскә таба аңа инеш койган урынга кадәр уза, 2,6 км инеш агымы буенча өскә таба бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м төньяк-көнчыгышка таба, урман полосасын, чокырны һәм инешнең текә ярын кисеп үтеп, 250 м көнчыгышка таба уза, 850 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м чокыр буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Норма участок урманчылыгындагы 38В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап бара, аннары 1,7 км Кирмән елгасы агымы буенча өскә таба уза, шуннан соң көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 38В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап, 200 м төньяк-көнчыгышка таба 38В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м төньяк-көнчыгышка таба, 350 м көньяк-көнчыгышка таба Красная Горка, Омар һәм Уразбахты авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Рус Кирмәне авылыннан 2,9 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 56 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Омар авыл җирлеге чиге Красная Горка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Красная Горка, Омар һәм Отарка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Керәшен Пакшины авылыннан 1,3 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 62 нче тоташу ноктасыннан алып 200 м көнбатышка таба урман полосасының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 700 м көнбатышка таба, чокырны кисеп үтеп, 400 м көньяк-көнбатышка таба, 50 м урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырларны кисеп үтеп, 1,2 км көньяк-көнбатышка таба, 200 м көнбатышка таба уза, 150 м урман массивы буйлап бара, аннары 3,5 км Пакшин елгасы агымы буенча аска таба аңа Кутушка елгасы койган урынга кадәр уза, 1,0 км бу

елга агымы буенча өскә таба бара, шуннан соң көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 700 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 300 м урман полосасының көньяк чиге буйлап, 250 м урман полосасы буйлап, 40 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап кибеп баручы инешкә кадәр аның текә ярын кисеп үтеп уза, аннары 2,2 км бу инешнең агымы буенча өскә таба бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба, текә ярны кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м урман полосасы буйлап, аны кисеп үтеп, 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 1,3 км төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап чокырларны һәм Кутушка елгасының текә ярын кисеп үтеп бара, 2,0 км Кутушка елгасы агымы буенча өскә таба уза, шуннан соң «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Соколка участок урманчылыгындагы 39В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап 40 м көнбатышка таба бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Мәскәү – Уфа» – Сикәнәс автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,7 км көнбатышка таба, агачлык-куаклык массивын кисеп үтеп, 500 м төньяк-көнчыгышка таба 56 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Омар авыл җирлеге чиге Отарка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Омар, Отарка һәм Соколка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Югары Сикәнәс авылыннан 3,8 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 61 нче тоташу ноктасыннан алып 2,7 км инеш агымы буенча аска таба ул кибеп баручы инеш белән кушылган урынга кадәр уза, 700 м аның агымы буенча өскә таба бара, аннары 400 м төньяк-көнбатышка таба чокыр төбе буйлап яр буендагы агачлык-куаклык массивын кисеп үтеп уза, чокырларны, инешләрне һәм аларның текә ярларын кисеп үтеп, 2,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,4 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 20 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 62 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Омар авыл җирлеге чиге Соколка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 61 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 200 м «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Соколка уча-

сток урманчылыгындагы 37 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м 37 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм 50 м көньяк-көнбатышка таба көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 100 м бу урманчылыктагы 3 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм 450 м көньякка таба көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 200 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 3,4 км, сынык сызык ясап, 3, 5, 8 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 850 м көньяк-көнбатышка таба бу урманчылыктагы 35 нче урман кварталы буенча уза, шуннан соң 700 м төньяк-көнбатышка таба бу урманчылыктагы 4 нче урман кварталы буенча бара, аннары 1,4 км кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба уза, шуннан соң 1,0 км көнчыгышка таба 4 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 2,1 км көньякка таба бу урманчылыктагы 7 нче, 12 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң 250 м көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 12 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары бу урманчылыктагы 18 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 250 м көньяк-көнбатышка таба, көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м көньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң, күлне кисеп үтеп, 100 м, бу урманчылыктагы 40 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 450 м бара, аннары бу урманчылыктагы 18 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 250 м көньякка таба, көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 300 м төньяк-көнчыгышка таба уза, күлне кисеп үтеп, 100 м, сынык сызык ясап, 1,4 км бу урманчылыктагы 18 нче, 19 нчы урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м һәм 19 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 300 м бара, шуннан соң көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, бу урманчылыктагы 19 нчы, 24 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м һәм 24 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м көньяк-көнбатышка таба, 50 м көньяк-көнчыгышка таба сазлыкны кисеп үтеп уза, 50 м саз-

лык буенча, сазлыкны, күлне һәм яр буендагы агачлык-куаклык массивын кисеп үтеп, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 20 м бу урманчылыктагы 42 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 150 м бу урманчылыктагы 31 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 31 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м төньяк-көнбатышка таба, төньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м көньяк-көнбатышка таба бара, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары урман массивы буенча 100 м төньяк-көнбатышка таба һәм 40 м көньяк-көнчыгышка таба, 50 м күл буенча бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, күлне берничә тапкыр кисеп үтеп, 200 м көньяк-көнчыгышка таба, күлне кисеп үтеп, 150 м төньяк-көнчыгышка таба, 150 м күлнең төньяк-көнбатыш яры буенча, сынык сызык ясап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 450 м көнчыгышка таба 31 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап Куйбышев сусаклагычының уң ярына кадәр бара, шуннан соң 2,3 км көньяк-көнбатышка таба Куйбышев сусаклагычының уң яры буенча уза, аннары 870 м көньяк-көнчыгышка таба Куйбышев сусаклагычы буенча Омар, Соколка авыл җирлекләре һәм Түбән Кама муниципаль районы чикләре тоташкан урында Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 440459,70, Y = 2263211,88 координаталы 64 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Омар авыл җирлеге чиге Түбән Кама муниципаль районы белән чиктәш җирдә 64 нче тоташу ноктасыннан алып Мамадыш муниципаль районы чиге буйлап Омар авыл җирлеге, Түбән Кама һәм Чистай муниципаль районнары чикләре тоташкан урында Вандовка авылыннан 6,8 км көньяк-көнчыгышта урнашкан X = 437876,44, Y = 2247017,01 координаталы 73 нче (60 нчы) тоташу ноктасына кадәр уза.

Омар авыл җирлеге чиге Чистай муниципаль районы белән чиктәш җирдә 73 нче (60 нчы) тоташу ноктасыннан алып Мамадыш муниципаль районы чиге буйлап 67 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

16) 24 нче кушымтада:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Отарка авыл җирлеге «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Красная Горка, Көек-Ерыкса, Омар, Соколка авыл җирлекләре һәм Алабуга муниципаль районы белән чиктәш.»;

б) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Отарка авыл җирлеге чиге Красная Горка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә «Мамадыш шәһәре» муниципаль берәмлеге, Красная Горка һәм Отарка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Красная Горка авылыннан 1,0 км көньякта урнашкан 59 нчы тоташу ноктасыннан алып 900 м Беркас елгасы агымы буенча өскә таба аңа кибеп баручы инеш койган урынга кадәр уза, 1,7 км инеш агымы буенча өскә таба бара, шуннан соң 1,7 км көньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман полосасын һәм Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп уза, аннары 100 м көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Соколка участок урманчылыгындагы 41В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м көнбатышка таба, 50 м көньякка таба уза, 41В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 650 м бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м көнбатышка таба, 50 м көньякка таба уза, шуннан соң 250 м көньяк-көнбатышка таба 41В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап, 100 м бу урманчылыктагы 37В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 5,3 км Пакшин елгасы агымы буенча аска таба уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 100 м көньяк-көнчыгышка таба, 400 м көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 700 м көньяк-көнчыгышка таба, 1,1 км көньяк-көнбатышка таба чокырларны берничә мәртәбә кисеп үтеп бара, аннары 100 м инеш агымы буенча өскә таба уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, чокырны кисеп үтеп, 400 м агачлык-куаклык массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап Красная Горка, Омар һәм Отарка авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Керәшен Пакшины авылыннан 1,3 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 62 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

в) бишенче абзацта «Малмыж» сүзен «Көек-Ерыкса» сүзенә алмаштырырга;

г) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Отарка авыл җирлеге чиге Көек-Ерыкса авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 37 нче тоташу ноктасыннан алып 650 м төньяк-көнчыгышка таба Нократ елгасы акваториясе буенча уза, шуннан соң 150 м көнчыгышка таба «Мамадыш урманчылы-

гы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 33В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап, инешне кисеп үтеп, 1,4 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 33В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап, сазлыкны кисеп үтеп, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м сазлык буенча, 600 м бу урманчылыктагы 32В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап Анзирка елгасына кадәр, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, Көек-Ерыкса, Отарка авыл җирлекләре һәм Алабуга муниципаль районы чикләре тоташкан урында Мамадыш шәһәренең төньяк чигеннән 3,2 км көнчыгышта урнашкан 38 нче тоташу ноктасына кадәр бара.»;

д) сигезенче абзацта «Отарка, Сикәнәс» сүзләрен «Омар, Отарка» сүзләренә алмаштырырга;

е) тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Отарка авыл җирлеге чиге Омар авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 61 нче тоташу ноктасыннан алып 2,7 км инеш агымы буенча аска таба кибеп баручы инеш белән кушылган урынга кадәр уза, 700 м инеш агымы буенча өскә таба бара, аннары 400 м төньяк-көнбатышка таба, яр буендагы агачлык-куаклык массивын кисеп үтеп, чокыр төбе буйлап уза, чокырларны, инешләрне һәм аларның текә ярларын кисеп үтеп, 2,7 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,4 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 20 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 62 нче тоташу ноктасына кадәр бара.»;

ж) унынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

17) 25 нче һәм 26 нчы кушымталарны үз көчләрен югалткан дип танырга;

18) 27 нче кушымтада:

а) икенче абзацта «Отарка, Сикәнәс» сүзләрен «Омар, Отарка» сүзләренә алмаштырырга;

б) дүртенче абзацта «Отарка, Сикәнәс» сүзләрен «Омар, Отарка» сүзләренә алмаштырырга;

в) алтынчы абзацта «Сикәнәс» сүзен «Омар» сүзенә алмаштырырга;

г) җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Соколка авыл җирлеге чиге Омар авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 61 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 200 м «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан

Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Соколка участок урманчылыгындагы 37 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м 37 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм 50 м көньяк-көнбатышка таба көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, 100 м бу урманчылыктагы 3 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап һәм 450 м көньякка таба көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 200 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 3,4 км, сынык сызык ясап, 3, 5, 8 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары 850 м көньяк-көнбатышка таба бу урманчылыктагы 35 нче урман кварталы буенча уза, шуннан соң 700 м төньяк-көнбатышка таба бу урманчылыктагы 4 нче урман кварталы буенча бара, аннары 1,4 км кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба уза, шуннан соң 1,0 км көнчыгышка таба 4 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 2,1 км көньякка таба бу урманчылыктагы 7 нче, 12 нче урман кварталларының көнбатыш чиге буйлап уза, шуннан соң 250 м көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 12 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары бу урманчылыктагы 18 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 250 м көньяк-көнбатышка таба, көньяк-көнбатыш чиге буйлап 100 м көньяк-көнчыгышка таба уза, шуннан соң, күлне кисеп үтеп, 100 м, бу урманчылыктагы 40 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 450 м бара, аннары бу урманчылыктагы 18 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, сынык сызык ясап, 250 м көньякка таба, көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 300 м төньяк-көнчыгышка таба уза, күлне кисеп үтеп, 100 м, сынык сызык ясап, 1,4 км бу урманчылыктагы 18 нче, 19 нчы урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м һәм 19 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 300 м бара, шуннан соң көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, бу урманчылыктагы 19 нчы, 24 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап 200 м, авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м һәм 24 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м көньяк-көнбатышка таба,

50 м көньяк-көнчыгышка таба сазлыкны кисеп үтеп уза, 50 м сазлык буенча, сазлыкны, күлне һәм яр буендагы агачлык-куаклык массивын кисеп үтеп, 500 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 20 м бу урманчылыктагы 42 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 150 м бу урманчылыктагы 31 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 31 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м төньяк-көнбатышка таба, төньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м көньяк-көнбатышка таба бара, 400 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары урман массивы буенча 100 м төньяк-көнбатышка таба һәм 40 м көньяк-көнчыгышка таба, 50 м күл буенча бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, күлне берничә тапкыр кисеп үтеп, 200 м көньяк-көнчыгышка таба, күлне кисеп үтеп, 150 м төньяк-көнчыгышка таба, 150 м күлнең төньяк-көнбатыш яры буенча, сынык сызык ясап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары, сынык сызык ясап, 450 м көнчыгышка таба 31 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап Куйбышев сусаклагычының уң ярына кадәр бара, шуннан соң 2,3 км көньяк-көнбатышка таба Куйбышев сусаклагычының уң яры буенча уза, аннары 870 м көньяк-көнчыгышка таба Куйбышев сусаклагычы буенча 64 нче тоташу ноктасына кадәр бара.»;

19) 28 нче кушымтада:

а) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Урта Кирмән авыл җирлеге чиге Красная Горка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Красная Горка, Урта Кирмән һәм Уразбахты авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Рус Кирмәне авылыннан 3,4 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 41 нче тоташу ноктасыннан алып «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Норма участок урманчылыгындагы 67 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м төньяк-көнчыгышка таба һәм көнчыгыш чиге буйлап 900 м төньякка таба уза, аннары 4,0 км төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, бу урманчылыктагы 66, 64, 58, 53 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап бара, шуннан соң 2,2 км көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, бу урманчылыктагы 51, 52, 54 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 500 м көньяк-көнбатышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан

соң 54 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 450 м көньяк-көнчыгышка таба һәм көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 350 м төньяк-көнчыгышка таба уза, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,1 км 54 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 40 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.»;

б) сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Урта Кирмән авыл җирлеге чиге Яке авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 42 нче тоташу ноктасыннан алып 200 м төньякка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Норма участок урманчылыгындагы 82 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 5,3 км төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, бу урманчылыктагы 82, 80, 79, 77, 76 нчы урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне һәм Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, профильле автомобиль юлы өчен бирелгән полосаны кисеп үтеп, бу урманчылыктагы 75 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 450 м бара, шуннан соң 700 м төньяк-көнчыгышка таба бу урманчылыктагы 75 нче, 74 нче урман кварталларының көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап уза, аннары 650 м төньяк-көнбатышка таба, 400 м төньяк-көнчыгышка таба, 300 м төньяк-көнбатышка таба 74 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап Кече Кирмән, Урта Кирмән һәм Яке авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Норма авылыннан 2,5 км көньяк-көнбатышта урнашкан 43 нче тоташу ноктасына кадәр бара.»;

20) 31 нче кушымтада:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Уразбахты авыл җирлеге Красная Горка, Омар, Урта Кирмән һәм Яке авыл җирлекләре белән чиктәш.»;

б) бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Уразбахты авыл җирлеге чиге Красная Горка авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Красная Горка, Омар һәм Уразбахты авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Рус Кирмәне авылыннан 2,9 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 56 нчы тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 450 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 1,9 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м урман полосасы буйлап, сынык сызык ясап, 400 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап кибеп ба-

ручы инешнең текә ярын кисеп үтеп уза, 800 м бу инеш агымы буенча аска таба бара, шуннан соң 100 м төньякка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Норма участок урманчылыгындагы 38В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 550 м төньякка таба, 150 м төньяк-көнбатышка таба, 400 м төньяк-көнчыгышка таба, 350 м төньякка таба һәм 38В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 50 м бара, шуннан соң инеш агымы буенча өскә таба 400 м уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 150 м чокыр буйлап, 100 м бу урманчылыктагы 37В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, 100 м урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м урман массивы буенча, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 38В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м уза, 37В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнбатыш чиге буйлап 50 м төньяк-көнбатышка таба, 200 м төньяк-көнчыгышка таба, Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 41 нче тоташу ноктасына кадәр бара.»;

в) алтынчы һәм җиденче абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

г) сигезенче һәм тугызынчы абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Уразбахты авыл җирлеге чиге Омар авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Омар, Уразбахты һәм Яке авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Уразбахты авылыннан 3,5 км көньяк-көнбатышта урнашкан 54 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,1 км урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 600 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап чокырны һәм инешнең текә ярын кисеп үтеп уза, 2,7 км бу инеш агымы буенча аска таба бара, аннары 4,4 км Омар елгасы агымы буенча өскә таба аңа инеш койган урынга кадәр уза, 2,6 км инеш агымы буенча өскә таба бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 200 м төньяк-көнчыгышка таба, урман полосасын, чокырны һәм инешнең текә ярын кисеп үтеп, 250 м көнчыгышка таба уза, 850 м урман полосасының төньяк чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м чокыр буйлап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Норма участок урманчылыгындагы 38В урман

кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап бара, аннары 1,7 км Кирмән елгасы агымы буенча өскә таба уза, шуннан соң көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м 38В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең төньяк чиге буйлап, 200 м төньяк-көнчыгышка таба 38В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк чиге буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 50 м төньяк-көнчыгышка таба, 350 м көньяк-көнчыгышка таба 56 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.

Уразбахты авыл җирлеге чиге Яке авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 42 нче тоташу ноктасыннан алып 850 м көньякка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Норма участок урманчылыгындагы 82 нче, 85 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап, 1,1 км көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 85 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,4 км, сынык сызык ясап, 85 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң 1,0 км төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, бу урманчылыктагы 85 нче, 84 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 900 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Усали участок урманчылыгындагы 77 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң 300 м көньяк-көнчыгышка таба 77 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 1,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 350 м чокыр төбе буйлап, 100 м агачлык-куаклык массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Норма участок урманчылыгындагы 38В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 1,7 км кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба Омар елгасына кадәр бара, аннары 1,3 км бу инеш агымы буенча өскә таба аңа кибеп баручы инеш койган җиргә кадәр уза, аннары 1,0 км бу инеш агымы буенча өскә таба уза, шуннан соң 150 м көньякка таба агачлык-куаклык массивы буенча, 200 м текә ярның көнбатыш чиге буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,1 км «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Усали участок урманчылыгындагы 81 нче урман кварталының аерым-

ланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 54 нче тоташу ноктасына кадәр бара.»;

21) 32 нче кушымтада:

а) икенче абзацта «Дегетле,» сүзен төшереп калдырырга, «Түбән Сон» сүзләреннән соң «, Яке» сүзен өстәргә;

б) бишенче абзацта «Дегетле, Түбән Сон һәм Урманчы» сүзләрен «Түбән Сон, Урманчы һәм Яке» сүзләренә алмаштырырга;

в) алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Урманчы авыл җирлеге чиге Яке авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 51 нче тоташу ноктасыннан алып 550 м көньяк-көнбатышка таба, 500 м көньякка таба «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Усали участок урманчылыгындагы 70 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, бу урманчылыктагы 72 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м көньяк-көнчыгышка таба, көнчыгыш чиге буйлап 1,0 км көньякка таба уза, аннары көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м бу урманчылыктагы 73 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 73 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м бара, шуннан соң 1,3 км көньяк-көнчыгышка таба «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бөрсет участок урманчылыгындагы 11 нче, 12 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 1,5 км көньяк-көнбатышка таба бу урманчылыктагы 12, 11, 19 нчы урман кварталларының көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 19 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 150 м бара, шуннан соң 950 м көньяк-көнчыгышка таба бу урманчылыктагы 19 нчы, 28 нче урман кварталларының көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап уза, аннары 200 м төньяк-көнчыгышка таба 28 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньякка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 28 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 500 м кибеп баручы инешкә кадәр уза, 250 м аның агымы буенча аска таба Кече Бөрсет елгасына кадәр бара, 4,3 км бу елга агымы буенча аска таба уза, аннары 1,1 км төньяк-көнчыгышка таба бу урманчылыктагы 53 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң 950 м көньяк-көнчыгышка таба бу урманчылыктагы 53 нче, 54 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 54 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш

чиге буйлап 1,5 км көнчыгышка таба, көнчыгыш чиге буйлап 250 м көньякка таба һәм көньяк чиге буйлап 1,7 км көнбатышка таба бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 1,3 км бу урманчылыктагы 54 нче, 53 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м ишелмә буенча Куйбышев сусаклагычының уң ярына кадәр уза, аннары 950 м көньяк-көнбатышка таба бу сусаклагычның акваториясе буенча Урманчы, Яке авыл җирлекләре һәм Чистай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 441877,43, Y = 2232106,21 координаталы 68 нче тоташу ноктасына кадәр бара.»;

22) 34 нче кушымтаның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шәдче авыл җирлеге чиге Көек-Ерыкса авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Дүсмәт, Көек-Ерыкса һәм Шәдче авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Яңа Комазан авылыннан 1,0 км төньяк-көнбатышта урнашкан 69 нчы тоташу ноктасыннан алып «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Комазан участок урманчылыгындагы 11 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап 700 м көнчыгышка таба, төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 2,0 км төньяк-көнбатышка таба, төньяк чиге буйлап 150 м көнбатышка таба уза, шуннан соң, сынык сызык ясап, 1,9 км төньяк-көнбатышка таба бу урманчылыктагы 3 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба 900 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 4,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, «Мамадыш – Кукмара» – Келәүш автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 19 нчы тоташу ноктасына кадәр уза.»;

23) 36 нчы кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мамадыш муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль
берәмлекләрнең территорияләре чикләрен
билгеләү һәм аларның статусы турында»
Татарстан Республикасы Законына
36 нчы кушымта

**Мамадыш муниципаль районының**
**«Яке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге**
**территориясе чигенең картографик тасвирламасы**

Әлеге картографик тасвирлама «Яке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чигенең карта-схемасын («Мамадыш

муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына 1 нче кушымта) тасвирлаудан гыйбарәт.

Яке авыл җирлеге Кече Кирмән, Түбән Сон, Омар, Урта Кирмән, Уразбахты, Урманчы авыл җирлекләре һәм Чистай муниципаль районы белән чиктәш.

## Мамадыш муниципаль районының «Яке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясе чиге

Яке авыл җирлеге чиге Кече Кирмән авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Кече Кирмән, Түбән Сон һәм Яке авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Түбән Яке авылыннан 1,5 км төньяк-көнбатышта урнашкан 44 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнчыгышка таба 850 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, урман массивын кисеп үтеп, 100 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 650 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Омар елгасын кисеп үтеп, 1,0 км «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Норма участок урманчылыгындагы 86 нчы урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,1 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап сынык сызык ясап уза, аннары бу урманчылыктагы 76 нчы урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап 50 м төньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 150 м төньяк-көнбатышка таба, 50 м төньяк-көнчыгышка таба, 76 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 400 м уза, аннары 50 м төньяк-көнбатышка таба профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 1,6 км бу урманчылыктагы 75 нче, 73 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап кибеп баручы инешне кисеп үтеп бара, шуннан соң 700 м төньякка таба 73 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап уза, аннары бу урманчылыктагы 72 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 800 м төньяк-көнбатышка таба, көнбатыш чиге буйлап 250 м төньяк-көнчыгышка таба һәм 800 м төньякка таба бара, шуннан соң 2,1 км төньяк-көнчыгышка таба, 72 нче, 70 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш һәм көнбатыш чикләре буйлап сынык сызык ясап уза, аннары 1,3 км

көньяк-көнчыгышка таба бу урманчылыктагы 70 нче, 71 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң 1,1 км көньякка таба 71 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары, сынык сызык ясап, 600 м көньяк-көнчыгышка таба бу урманчылыктагы 74 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап Кече Кирмән, Урта Кирмән һәм Яке авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Норма авылыннан 2,5 км көньяк-көнбатышта урнашкан 43 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Яке авыл җирлеге чиге Урта Кирмән авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Урта Кирмән, Уразбахты һәм Яке авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Урта Кирмән авылыннан 3,9 км көньякта урнашкан 42 нче тоташу ноктасыннан алып 200 м төньякка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Норма участок урманчылыгындагы 82 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 5,3 км төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, бу урманчылыктагы 82, 80, 79, 77, 76 нчы урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, кибеп баручы инешне һәм Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, профильле автомобиль юлы өчен бирелгән полосаны кисеп үтеп, бу урманчылыктагы 75 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 450 м бара, шуннан соң 700 м төньяк-көнчыгышка таба бу урманчылыктагы 75 нче, 74 нче урман кварталларының көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап уза, аннары 650 м төньяк-көнбатышка таба, 400 м төньяк-көнчыгышка таба, 300 м төньяк-көнбатышка таба 74 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 43 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Яке авыл җирлеге чиге Уразбахты авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 42 нче тоташу ноктасыннан алып 850 м көньякка таба «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Норма участок урманчылыгындагы 82 нче, 85 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап, 1,1 км көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 85 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,4 км, сынык сызык ясап, 85 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң 1,0 км төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, бу урманчылыктагы 85 нче, 84 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 900 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м «Кама урманчылы-

гы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Усали участок урманчылыгындагы 77 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң 300 м көньяк-көнчыгышка таба 77 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 1,2 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, 350 м чокыр төбе буйлап, 100 м агачлык-куаклык массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м «Мамадыш урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Норма участок урманчылыгындагы 38В урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 1,7 км кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба Омар елгасына кадәр бара, аннары 1,3 км бу инеш агымы буенча өскә таба аңа кибеп баручы инеш койган җиргә кадәр уза, аннары 1,0 км бу инеш агымы буенча өскә таба уза, шуннан соң 150 м көньякка таба агачлык-куаклык массивы буенча, 200 м текә ярның көнбатыш чиге буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,1 км «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Усали участок урманчылыгындагы 81 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Омар, Уразбахты һәм Яке авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Уразбахты авылыннан 3,5 км көньяк-көнбатышта урнашкан 54 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Яке авыл җирлеге чиге Омар авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Омар, Яке авыл җирлекләре һәм Чистай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 439751,74, Y = 2238510,36 координаталы 67 нче тоташу ноктасыннан алып 1,4 км төньяк-көнбатышка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча уза, шуннан соң 950 м көнбатышка таба бу сусаклагычның уң яры буйлап бара, аннары төньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 750 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сазлыкны һәм агачлык-куаклык массивын кисеп үтеп, 100 м агачлык-куаклык массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,1 км «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бөрсет участок урманчылыгындагы 55 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң 4,2 км Заборный елгасы агымы буенча өскә таба бара, аннары 4,3 км инеш агымы буенча өскә таба уза, шуннан соң 350 м

төньякка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 600 м инеш агымы буенча өскә таба аңа кибеп баручы инеш койган урынга кадәр бара, 2,1 км кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 250 м бу урманчылыктагы 71 нче урман кварталының аерымланган кишәрлегенең көнчыгыш чиге буйлап кибеп баручы инешкә кадәр бара, шуннан соң 1,5 км кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба ул икенче кибеп баручы инеш белән кушылган урынга кадәр уза, аннары 1,3 км кибеп баручы инеш агымы буенча өскә таба бара, шуннан соң 1,4 км көнчыгышка таба авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары 650 м кибеп баручы инеш агымы буенча аска таба бара, шуннан соң 1,2 км инеш агымы буенча аска таба уза, аннары төньяк-көнчыгышка таба 300 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 30 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 54 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Яке авыл җирлеге чиге Чистай муниципаль районы белән чиктәш җирдә 67 нче тоташу ноктасыннан алып Мамадыш муниципаль районы чиге буенча Урманчы, Яке авыл җирлекләре һәм Чистай муниципаль районы чикләре тоташкан урында Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 441877,43, Y = 2232106,21 координаталы 68 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Яке авыл җирлеге чиге Урманчы авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Түбән Сон, Урманчы һәм Яке авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Дегетле авылыннан 3,1 км көньяк-көнбатышта урнашкан 51 нче тоташу ноктасыннан алып 550 м көньяк-көнбатышка таба, 500 м көньякка таба «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Усали участок урманчылыгындагы 70 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, бу урманчылыктагы 72 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 500 м көньяк-көнчыгышка таба, көнчыгыш чиге буйлап 1,0 км көньякка таба уза, аннары көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 500 м бу урманчылыктагы 73 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 73 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м бара, шуннан соң 1,3 км көньяк-көнчыгышка таба «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Бөрсет участок урманчылыгындагы 11 нче, 12 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 1,5 км көньяк-көнбатышка таба бу урманчылыктагы 12, 11, 19 нчы урман кварталларының

көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 19 нчы урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 150 м бара, шуннан соң 950 м көньяк-көнчыгышка таба бу урманчылыктагы 19 нчы, 28 нче урман кварталларының көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап уза, аннары 200 м төньяк-көнчыгышка таба 28 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньякка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 28 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 500 м кибеп баручы инешкә кадәр уза, 250 м аның агымы буенча аска таба Кече Бөрсет елгасына кадәр бара, 4,3 км бу елга агымы буенча аска таба уза, аннары 1,1 км төньяк-көнчыгышка таба бу урманчылыктагы 53 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң 950 м көньяк-көнчыгышка таба бу урманчылыктагы 53 нче, 54 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары 54 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 1,5 км көнчыгышка таба, көнчыгыш чиге буйлап 250 м көньякка таба һәм көньяк чиге буйлап 1,7 км көнбатышка таба бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 1,3 км бу урманчылыктагы 54 нче, 53 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 50 м ишелмә буенча Куйбышев сусаклагычының уң ярына кадәр уза, аннары 950 м көньяк-көнбатышка таба бу сусаклагычның акваториясе буенча 68 нче тоташу ноктасына кадәр бара.

Яке авыл җирлеге чиге Түбән Сон авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 44 нче тоташу ноктасыннан алып көньякка таба 300 м «Кама урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Усали участок урманчылыгындагы 43 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 1,4 км бу урманчылыктагы 43, 47, 48 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 1,3 км көньяк-көнчыгышка таба бу урманчылыктагы 48 нче, 50 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары 50 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 150 м көньякка таба, көньяк чиге буйлап 1,5 км көнбатышка таба, көньяк-көнбатыш чиге буйлап 800 м төньяк-көнбатышка таба Дегетле елгасын кисеп үтеп уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 1,3 км бу урманчылыктагы 49 нчы, 52 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, сынык сызык ясап, 1,8 км бу

урманчылыктагы 52 нче, 54 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап кибеп баручы инешне кисеп үтеп бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 1,9 км бу урманчылыктагы 59 нчы, 62 нче урман кварталларының төньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 1,2 км бу урманчылыктагы 62 нче, 64 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш һәм көнчыгыш чикләре буйлап бара, аннары 400 м көнбатышка таба 64 нче урман кварталының көньяк чиге буйлап уза, шуннан соң 1,0 км көньякка таба, сынык сызык ясап, бу урманчылыктагы 67 нче урман кварталының көнчыгыш чиге буйлап 51 нче тоташу ноктасына кадәр бара.».

**5 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 20 мае
№ 36-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 768. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 8[1] статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 27 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш), № 12 (III өлеш); 2005, № 2; 2006, № 2 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 5 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш);

Ватаным Татарстан, 2013, 19 гыйнвар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 1 пунктындагы унберенче абзацта «хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге» сүзләреннән соң «, онкология авырулары» сүзләрен өстәргә;

2) $8^1$ статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$8^1$ статья. **Хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге, онкология авырулары белән авыручы затларга социаль ярдәм чаралары**

1. Хроник бөер эшчәнлеге җитешсезлеге белән авыручы, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумының икеләтә күләменнән кимрәк булган затларга амбулатор гемодиализ үтү урынына бару һәм яшәү урынына кире кайту буенча транспорт чыгымнары компенсацияләнә.

2. Онкология авырулары белән авыручы, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумының икеләтә күләменнән кимрәк булган затларга махсуслаштырылган онкология ярдәме күрсәтә торган Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау учреждениеләрендәге дәвалану урынына бару һәм яшәү урынына кире кайту буенча транспорт чыгымнары компенсацияләнә.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның гамәли көче 2013 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 20 мае
№ 37-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

## 769. «Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 27 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре турында» 2005 елның 29 декабрендәге 134-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш); 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, №3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяның 4 өлешендәге икенче абзацта «Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары тарафыннан» сүзләреннән соң «казна учреждениеләре рәвешендә» сүзләрен өстәргә, «, салымнар һәм җыемнар турындагы законнарда каралган салымнарны һәм җыемнарны түләгәннән соң,» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 10 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10 статья. **Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару хезмәтләре һәм һәлакәттән коткару формированиеләре эшчәнлеген финанс ягыннан тәэмин итү**

1. Казна учреждениеләре рәвешендә төзелгән Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару профессиональ хезмәтләре, һәлакәттән коткару профессиональ формированиеләре эшчәнлеген, шул исәптән коткаручыларның хокукларын һәм гарантияләрен финанс ягыннан тәэмин итү, шулай ук бюджет һәм автоном учреждениеләр рәвешендә төзелгән Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару профессиональ хезмәтләре, һәлакәттән коткару профессиональ формированиеләре тарафыннан дәүләт (муниципаль) йөкләмәләренең башкарылуын, шул исәптән коткаручыларның хокукларын һәм гарантияләрен финанс ягыннан тәэмин итү Татарстан Республикасы бюджет системасының тиешле бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2. Бюджет һәм автоном учреждениеләр рәвешендә төзелгән Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару профессиональ хезмәтләренең, һәлакәттән коткару профессиональ формированиеләренең дәүләт (муниципаль) йөкләмәсен башкарудан тыш гамәлгә ашырыла торган эшчәнлеген, шул исәптән коткаручыларның хокукларын һәм гарантияләрен финанс ягыннан тәэмин итү объектларга һәм территорияләргә хезмәт күрсәтү шартнамәләрен башкарудан керә торган акчалар исәбеннән шартнамә нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Башка оештыру-хокукый рәвешләрдә төзелгән Татарстан Республикасы һәлакәттән коткару профессиональ хезмәтләренең, һәлакәттән коткару профессиональ формированиеләренең эшчәнлеген, шул исәптән коткаручыларның хокукларын һәм гарантияләрен финанс ягыннан тәэмин итү уставта каралган эшчәнлекне башкару һәм Россия Федерациясе законнарына каршы килми торган бүтән финанслау чыганаклары исәбеннән шартнамә нигезендә гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасы һәлакәттән коткаруның штатка кермәгән һәм иҗтимагый формированиеләре эшчәнлеген, шул исәптән коткаручыларның хокукларын һәм гарантияләрен финанс ягыннан тәэмин итү күрсәтелгән формированиеләрне төзегән оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр акчалары исәбеннән, шулай ук Россия Федерациясе законнарына каршы килми торган бүтән финанслау чыганаклары исәбеннән гамәлгә ашырыла.»;

3) 15 статьяның 1 өлешендә «Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән хезмәт өчен түләүнең кимендә 500 минималь күләме суммасында» сүзләрен «кимендә 20 000 сум» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 20 мае
№ 38-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 770. «Муниципаль районнарның һәм «Чаллы шәһәре» шәһәр округының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 27 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Муниципаль районнарның һәм «Чаллы шәһәре» шәһәр округының җирле үзидарә органнарына хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2012 елның 13 гыйнварындагы 9-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 1) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемдә «Чаллы шәһәре» шәһәр округының» сүзләрен «шәһәр округларының» сүзләренә алмаштырырга;

2) преамбулада «Чаллы шәһәре» шәһәр округының» сүзләрен «шәһәр округларының» сүзләренә алмаштырырга;

3) 1 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 4 – 6 пунктлар өстәргә:

«4) хуҗасыз йорт хайваннарын аулау;

5) хуҗасыз йорт хайваннарын вакытлыча тоту пунктында асрау;

6) хуҗасыз йорт хайваннары исәбен җайга салу (хуҗасыз йорт хайваннарын стерильләштерү (кастрация ясау), артык агрессив хуҗасыз йорт хайваннарын, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләре яисә көчле интегүләр китереп чыгара торган, дәвалап булмаслык чирләре ачыкланган хуҗасыз йорт хайваннарын юк итү).»;

4) 2 статьяда:

а) беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 өлешенең 1 – 3 пунктларында каралган дәүләт вәкаләтләре Татарстан Республикасында түбәндәге муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына бирелә:»;

б) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

«2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 өлешенең 4 – 6 пунктларында каралган дәүләт вәкаләтләре әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына, шулай ук Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына бирелә.»;

5) 5 статьяда:

а) 1 өлештә «Чаллы шәһәре» шәһәр округы» сүзләрен «шәһәр округлары» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле бюджетларга бирелә торган субвенцияләрнең күләмен исәпләү әлеге Законга кушымта нигезендә Хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләр күләмен исәпләү методикасына таянып гамәлгә ашырыла.»;

6) кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль районнарның
һәм шәһәр округларының
җирле үзидарә органнарына хайваннар
чирләрен кисәтү һәм бетерү,
аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне
оештыру өлкәсендә Татарстан
Республикасының аерым дәүләт
вәкаләтләрен бирү турында»
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

# ХАЙВАННАР ЧИРЛӘРЕН КИСӘТҮ ҺӘМ БЕТЕРҮ, АЛАРНЫ ДӘВАЛАУ, КЕШЕ ҺӘМ ХАЙВАННАР ӨЧЕН УРТАК ЧИРЛӘРДӘН ХАЛЫКНЫ ЯКЛАУ ЧАРАЛАРЫН ҮТКӘРҮНЕ ОЕШТЫРУ ӨЛКӘСЕНДӘ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АЕРЫМ ДӘҮЛӘТ ВӘКАЛӘТЛӘРЕН ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫ ТАРАФЫННАН ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ӨЧЕН ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БЮДЖЕТЫННАН МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘР БЮДЖЕТЛАРЫНА БИРЕЛӘ ТОРГАН СУБВЕНЦИЯЛӘР КҮЛӘМЕН ИСӘПЛӘҮ МЕТОДИКАСЫ

1. Әлеге Методика Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде.

2. Методика хайваннар чирләрен кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең күләмен исәпләү тәртибен билгеләү өчен каралган.

3. Тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру өчен муниципаль берәмлекләр бюджетларына бирелә торган субвенцияләрнең гомуми күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$S = \sum_{i=1}^{m} HP_i,$$

монда:

S – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга муниципаль берәмлекләр бюджетларына субвенцияләрнең гомуми күләме;

$НР_i$ – дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга i-муниципаль берәмлеге бюджетына субвенцияләр күләме;

m – Татарстан Республикасында дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бюджетларына субвенцияләр бирелә торган муниципаль берәмлекләр саны.

4. Дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга i-муниципаль берәмлеге бюджетына субвенцияләр күләме мал-туарның түләмә чире каберлекләрен һәм биотермик чокырларны карап тотуга, аларның куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын күрүгә, биотермик чокырларны консервацияләүгә, шулай ук хуҗасыз йорт хайваннарын аулауга, аларны вакытлыча тоту пунктында асрауга, хуҗасыз йорт хайваннарының исәбен җайга салуга норматив чыгымнардан чыгып билгеләнә:

$$НР_i = НР_{БЯ_i} + НР_{СС_i} + НР_{ОБ_i},$$

монда:

$НР_{БЯ_i}$ – i-муниципаль берәмлегендә биотермик чокырларны карап тотуга, аларның куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын күрүгә һәм аларны консервацияләүгә норматив чыгымнар;

$НР_{СС_i}$ – i-муниципаль берәмлегендә мал-туарның түләмә чире каберлекләрен карап тотуга, аларның куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын күрүгә норматив чыгымнар;

$НР_{ОБ_i}$ – i-муниципаль берәмлегендә хуҗасыз йорт хайваннарын аулауга, аларны вакытлыча тоту пунктында асрауга, хуҗасыз йорт хайваннарының исәбен җайга салуга норматив чыгымнар.

5. Мал-туарның түләмә чире каберлекләрен һәм биотермик чокырларны карап тоту, аларның куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын күрү, биотермик чокырларны консервацияләү чыгымнарына түбәндәгеләр керә:

1) биотермик чокыр өчен:

а) биотермик чокыр территориясен һәм конструкциясен дезинфекцияләү;

б) белгечне кирәкле инвентарь эш кораллары һәм махсуслаштырылган кием белән тәэмин итү;

в) биотермик чокырга хезмәт күрсәтү, аны эксплуатацияләү һәм консервацияләү, моңа биотермик чокыр конструкциясенә агымдагы ремонт, территория җыештыру да керә;

2) мал-туарның түләмә чире каберлеге өчен – мал-туарның түләмә чире каберлегенә хезмәт күрсәтү, моңа мал-

туарның түләмә чире каберлегенә агымдагы ремонт, территория җыештыру да керә.

6. Хуҗасыз йорт хайваннарын аулау, аларны вакытлыча тоту пунктында асрау, хуҗасыз йорт хайваннарының исәбен җайга салу чыгымнарына түбәндәгеләр керә:

а) хуҗасыз йорт хайваннарын аулау, шул исәптән аларны вакытлыча тоту пунктына озату;

б) хуҗасыз йорт хайваннарын вакытлыча тоту пунктында асрау;

в) хуҗасыз йорт хайваннарын стерильләштерү (кастрация ясау);

г) артык агрессив хуҗасыз йорт хайваннарын, кеше һәм хайваннар өчен уртак чирләре яисә көчле интегүләр китереп чыгара торган, дәвалап булмаслык чирләре ачыкланган хуҗасыз йорт хайваннарын юк итү һәм утильләштерү (алга таба – агрессив һәм (яисә) авыру хуҗасыз йорт хайваннарын юк итү һәм утильләштерү).

7. Биотермик чокыр территориясен һәм конструкциясен дезинфекцияләүгә чыгымнар ветеринария хезмәте күрсәтүләргә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең ветеринария эше өлкәсендә вәкаләтле органы тарафыннан расланган бәяләр нигезендә, товарлар һәм халыкка хезмәт күрсәтүләр бәясе индексын исәпкә алып, авыл хуҗалыгы оешмалары буенча бинаның 1000 кв. метрына бәяләрдән чыгып исәпләп чыгарыла.

8. Белгечне кирәкле инвентарь эш кораллары һәм махсуслаштырылган кием белән тәэмин итүгә чыгымнар ветеринария хезмәте учреждениеләрен карап тотуга чыгымнарның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары белән расланган натураль нормаларыннан (йомшак инвентарь һәм махсус кием-салым кулланылышы нормасы, дезинфекция препаратлары кулланылышы нормасы, биналарны җыештыруга юу чараларын сарыф итү нормасы һәм башкалар) чыгып исәпләп чыгарыла.

9. Мал-туарның түләмә чире каберлекләренә хезмәт күрсәтү чыгымнары һәм биотермик чокырларга хезмәт күрсәтү, аларны эксплуатацияләү, консервацияләү чыгымнары, төзелеш-монтаж эшләре бәясенең үзгәрү индексын кулланып, тышкы төзекләндерү объектларын ремонтлауга һәм карап тотуга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары белән расланган уртача еллык тотылган акчалар нормативларыннан чыгып исәпләп чыгарыла.

10. Хуҗасыз йорт хайваннарын аулау, шул исәптән аларны вакытлыча тоту пунктына озату чыгымнары хуҗасыз бер йорт хайванын аулауга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән расланган чыгымнар нормативыннан һәм узган елда ауланган хуҗасыз йорт хайваннары саныннан чыгып исәпләп чыгарыла.

11. Хуҗасыз йорт хайваннарын асрауга чыгымнар вакытлыча тоту пунктында хуҗасыз бер йорт хайванын асрауга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән расланган чыгымнар нормативыннан һәм вакытлыча тоту пунктында узган елда асралган хуҗасыз йорт хайваннары саныннан чыгып исәпләп чыгарыла.

12. Хуҗасыз йорт хайваннарының исәбен җайга салуга чыгымнар хуҗасыз бер йорт хайванын стерильләштерүгә (кастрация ясауга), агрессив һәм (яисә) авыру хуҗасыз бер йорт хайванын юк итүгә һәм утильләштерүгә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән расланган чыгымнар нормативларыннан һәм узган елда стерильләштерелгән (кастрация ясалган) һәм юк ителгән хуҗасыз йорт хайваннары саныннан чыгып исәпләп чыгарыла.

13. I-муниципаль берәмлегендә мал-туарның түләмә чире каберлекләрен һәм биотермик чокырларны карап тотуга, аларның куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын күрүгә, биотермик чокырларны консервацияләүгә норматив чыгымнар түбәндәге формулалар буенча билгеләнә:

1) биотермик чокырлар өчен:

$$НР_{БЯ_i} = \sum_{j=1}^{n} (НД_j^i + НИ_j^i + НЭ_j^i),$$

монда:

$НД_j^i$ – i-муниципаль берәмлегендә j-биотермик чокыры территориясен һәм конструкциясен дезинфекцияләүгә норматив чыгымнар;

$НИ_j^i$ – i-муниципаль берәмлегендә j-биотермик чокыры инвентарена норматив чыгымнар;

$НЭ_j^i$ – i-муниципаль берәмлегендә j-биотермик чокырына хезмәт күрсәтүгә, аны эксплуатацияләүгә һәм консервацияләүгә норматив чыгымнар;

n – i-муниципаль берәмлегендә биотермик чокырлар саны;

2) мал-туарның түләмә чире каберлекләре өчен:

$$HP_{CC_i} = \sum_{j=1}^{n} HO_j^i,$$

монда:

$HO_j^i$ – i-муниципаль берәмлегендә мал-туарның түләмә чире j-каберлегенә хезмәт күрсәтүгә норматив чыгымнар;

n – i-муниципаль берәмлегендә мал-туарның түләмә чире каберлекләре саны.

14. I-муниципаль берәмлегендә хуҗасыз йорт хайваннарын аулауга, аларны вакытлыча тоту пунктында асрауга, хуҗасыз йорт хайваннарының исәбен җайга салуга норматив чыгымнар түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$H_{ОБ_i} = (HP_{О_i} + HP_{С_i} + HP_{К_i} + HP_{Э_i}),$$

монда:

$HP_{О_i}$ – i-муниципаль берәмлегендә хуҗасыз йорт хайваннарын аулауга, шул исәптән аларны вакытлыча тоту пунктына озатуга норматив чыгымнар;

$HP_{С_i}$ – i-муниципаль берәмлегендә хуҗасыз йорт хайваннарын вакытлыча тоту пунктында асрауга норматив чыгымнар;

$HP_{К_i}$ – i-муниципаль берәмлегендә хуҗасыз йорт хайваннарын стерильләштерүгә (кастрация ясауга) норматив чыгымнар;

$HP_{Э_i}$ – i-муниципаль берәмлегендә агрессив һәм (яисә) авыру хуҗасыз йорт хайваннарын юк итүгә, утильләштерүгә норматив чыгымнар.

15. I-муниципаль берәмлегендә хуҗасыз йорт хайваннарын аулауга норматив чыгымнар түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$HP_{О_i} = К1_i \times HP_{О},$$

монда:

$К1_i$ – i-муниципаль берәмлегендә узган елда ауланган хуҗасыз йорт хайваннарының саны;

$HP_{О}$ – хуҗасыз бер йорт хайванын аулауга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән расланган норматив чыгымнар.

16. I-муниципаль берәмлегендә хуҗасыз йорт хайваннарын вакытлыча тоту пунктында асрауга норматив чыгымнар түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$НРс_i = К2_i \times НРс,$$

монда:

$К2_i$ – i-муниципаль берәмлегендә вакытлыча тоту пунктында узган елда асралган хуҗасыз йорт хайваннары саны;

*НРс* – вакытлыча тоту пунктында хуҗасыз бер йорт хайванын асрауга Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән расланган норматив чыгымнар.

17. I-муниципаль берәмлегендә хуҗасыз йорт хайваннарын стерильләштерүгә (кастрация ясауга) норматив чыгымнар түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$НРк_i = К3_i + НРк,$$

монда:

$К3_i$ – i-муниципаль берәмлегендә узган елда стерильләштерелгән (кастрация ясалган) хуҗасыз йорт хайваннары саны;

*НРк* – хуҗасыз бер йорт хайванын стерильләштерүгә (кастрация ясауга) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән расланган норматив чыгымнар.

18. I-муниципаль берәмлегендә агрессив һәм (яисә) авыру хуҗасыз йорт хайваннарын юк итүгә һәм (яисә) утильләштерүгә норматив чыгымнар түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$НРэ_i = К4_i \times НРэ,$$

монда:

$К4_i$ – i-муниципаль берәмлегендә узган елда юк ителгән һәм утильләштерелгән хуҗасыз йорт хайваннары саны;

*НРэ* – хуҗасыз бер йорт хайванын юк итүгә һәм утильләштерүгә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән расланган норматив чыгымнар.».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, шушы статьяның бу Закон рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә торган 2 өлешеннән тыш, 2014 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

2. 2013 елның 1 сентябренә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 20 мае
№ 39-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 771. «Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытын чикләүне билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 27 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә алкоголь продукциясен ваклап сату вакытын чикләүне билгеләү турында» 2010 елның 22 ноябрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 11; 2011, № 10 (I өлеш) «сыра эчемлекләрен» сүзләреннән соң «, сидрны, пуарены, әче балны» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 20 мае
№ 40-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 772. «Татарстан Республикасында торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүнең төбәк стандартлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 27 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында торак урыны һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләүнең төбәк стандартлары турында» 2005 елның 30 декабрендәге 138-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 12 (IV өлеш); 2007, № 4; 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 1, № 7 – 8 (I өлеш); 2011, № 12 (I өлеш), Ватаным Татарстан, 2013, 20 апрель) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Субсидия исәпләп чыгару өчен кулланыла торган торак урыны норматив мәйданының төбәк стандарты түбәндәгеләргә карата билгеләнә:

ялгыз яшәүче гражданга;

ике кешедән торган гаиләнең бер әгъзасына;

өч кешедән торган гаиләнең бер әгъзасына;

дүрт кешедән торган гаиләнең бер әгъзасына;

биш һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаиләнең бер әгъзасына.»;

2) 3 статьяның 2 өлешендә:

а) өченче абзацта «җылылык белән тәэмин итү» сүзләрен «җылыту» сүзенә алмаштырырга;

б) дүртенче абзацта «җылылык белән тәэмин итү» сүзләрен «җылыту» сүзенә алмаштырырга;

в) бишенче абзацта «җылылык белән тәэмин итү» сүзләрен «җылыту» сүзенә алмаштырырга;

3) 6 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:

«3. Торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр хакының төбәк стандартлары җылыту һәм җылыту арасындагы чорларга, шулай ук за-

коннарда каралган бүтән очракларда дифференциацияле билгеләнә, коммуналь ресурсларга тарифлар календарь буенча бүленгән очракта, шул исәптән мондый бүленеш буенча да билгеләнергә мөмкин.»;

4) 1 нче кушымтаның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр хакының төбәк стандартлары күләмнәре түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$Cij = \sum_{c=1}^{n} (Tc \times (Ncj_{тор} + (Ncj_{бер} \times Si_{бер}) \times Kcj) + \sum_{L=1}^{m} (TL \times KLj \times Si),$$

монда:

Cij – хезмәт күрсәтүләрнең j-исемлегә буенча торак-коммуналь хезмәт күрсәтүләр хакының i кешедән торган гаиләнең бер әгъзасына төбәк стандарты күләме;

Tc(L) – коммуналь хезмәт (торак хезмәте) күрсәтүгә тариф (бәя);

$Ncj_{тор}$ – торак урыннарында j-исемлек буенча коммуналь хезмәт күрсәтүне күпфатирлы йортлар һәм торак йортлар өчен куллану нормативы;

$Ncj_{бер}$ – j-исемлек буенча коммуналь хезмәт күрсәтүне гомумйорт ихтыяҗлары өчен куллану нормативы;

$Si_{бер}$ - күпфатирлы йортларда уртак мөлкәт составына керә торган урыннарның i кешедән торган гаиләнең бер әгъзасына туры килә торган мәйданы;

Kc(L)j – муниципаль берәмлек торак фондының хезмәт күрсәтүләрнең j-исемлегә буенча коммуналь хезмәт (торак хезмәте) күрсәтү белән тәэмин ителеше коэффициенты;

n – коммуналь хезмәт күрсәтүләр саны;

m – торак хезмәте күрсәтүләр саны;

j – муниципаль берәмлектәге уртача шартларга туры килә торган торак фондында күрсәтелә торган хезмәтләр исемлекләре.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 20 мае
№ 41-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 773. Биектау муниципаль районының Биектау һәм Красносельский авыл җирлекләре территорияләре чикләрен үзгәртү, аерым муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору һәм «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 27 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Биектау муниципаль районы составына керүче «Биектау авыл җирлеге» һәм «Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен әлеге җирлекләрдәге халыкның вәкиллекле органнары аша белдерелгән ризалыгы белән әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәртергә.

**2 статья**

Биектау муниципаль районы составына керүче түбәндәге муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп корырга:

1) әлеге Законның 1 статьясында каралган үзгәрешләрне исәпкә алып билгеләнгән чикләрдә «Биектау авыл җирлеге»н һәм «Пермяк авыл җирлеге»н әлеге җирлекләрдәге халыкның вәкиллекле органнары аша белдерелгән ризалыгы белән күрсәтелгән җирлекләрне административ үзәге Биектау авылы булган «Биектау авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенә берләштерү юлы белән;

мобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көньякка таба, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м, сынык сызык ясап, 80 нче урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 50 м сазлык буенча, 150 м көньяк-көнбатышка таба, 100 м, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, агачлык-куаклыклар массивы буйлап, Каменка елгасын кисеп үтеп, 3,5 км, сынык сызык ясап, 80, 87, 86 нчы урман кварталларының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Казан – Малмыж автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, аннары көньяк-көнбатышка таба 100 м әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 350 м «Шәһәр яны урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Биектау участок урманчылыгындагы 90 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көнбатышка таба 90 нчы урман кварталының көньяк чиге буйлап 450 м, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 300 м, сынык сызык ясап, 90 нчы урман кварталының көньяк һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 2,1 км, сынык сызык ясап, Биектау авылы – Биектау тимер юл станциясе поселогы автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 89, 88 нче урман кварталларының көньяк-көнчыгыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,9 км, сынык сызык ясап, 83, 74 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буенча бара, шуннан соң көньякка таба 100 м күмәк бакчаларның төньяк-көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап, инешне кисеп үтеп, 1,4 км, сынык сызык ясап, 82 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш, көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш чикләре буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 200 м урман массивы буйлап, 50 м сәнәгать объектының көнбатыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап бара, шуннан соң көньякка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 50 м урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м урман массивы буйлап бара, шуннан соң көнчыгышка

таба 100 м, профильле автомобиль юлына һәм Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаларны кисеп үтеп, 59 нчы урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 450 м Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, шуннан соң төньяк-көнчыгышка таба 59 нчы урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнбатыш чиге буйлап 700 м уза, аннары, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, сынык сызык ясап, 200 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң 450 м көньяк-көнбатышка таба әлеге тимер юлга бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнчыгышка таба 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 50 м төньяк-көнчыгышка таба бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 750 м, сынык сызык ясап, 103 нче урман кварталының көньяк-көнбатыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 102 нче урман кварталының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 650 м бара, шуннан соң көнбатышка таба 900 м, сынык сызык ясап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 101 нче урман кварталының төньяк һәм төньяк-көнбатыш чикләре буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 101, 71 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап 200 м бара, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 50 м урман массивының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 950 м Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, әлеге тимер юлның тармагын кисеп үтеп, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба сәнәгать объектының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 100 м һәм көньяк-көнбатышка таба көньяк-көнчыгыш чиге буйлап 50 м уза, Горький тимер юлы тармагын кисеп үтеп, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба, сынык сызык ясап, 71 нче урман кварталының көнчыгыш һәм көньяк чикләре буйлап 500 м бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 1,4 км, сынык сызык ясап, сәнәгать объектының төньяк-көнбатыш, төньяк-көнчыгыш, көньяк-көнчыгыш һәм көньяк-көнбатыш чикләре буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 192 нче урман кварталының аерымланган кишәрлекнең төньяк-көнчыгыш чиге буйлап 40 м бара, аннары төньякка таба 30 м Киндерле тимер юл разъезды поселогы – Крутушка шифаханәсе автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 150 м авыл

хуҗалыгы җирләре буйлап бара, Киндерле тимер юл разъезды поселогы – Крутушка шифаханәсе автомобиль юлына һәм профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаларны кисеп үтеп, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 300 м профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 400 м, сынык сызык ясап, агачлык-куаклыклар массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, профильле автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң төньяк-көнбатышка таба 50 м Мәскәү – Уфа федераль автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба, әлеге автомобиль юлына бүлеп бирелгән полосаны һәм агачлык-куаклыклар массивын кисеп үтеп, 50 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Казан шәһәре муниципаль берәмлеге, Биектау һәм Красносельский авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Березовка поселогыннан 1,7 км көньяк-көнбатышта урнашкан 55 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

9) 18 нче кушымтада:

а) икенче абзацта «җирлеге» сүзеннән соң «Бөреле,» сүзен өстәргә, «Сосновка,» сүзен төшереп калдырырга;

б) дүртенче абзацта «Мүлмә, Сосновка» сүзләрен «Бөреле, Мүлмә» сүзләренә алмаштырырга;

в) бишенче абзацта «Сосновка» сүзен «Бөреле» сүзенә, «Мүлмә, Сосновка» сүзләрен «Бөреле, Мүлмә» сүзләренә алмаштырырга;

10) 19 нчы һәм 22 нче кушымталарны үз көчләрен югалткан дип танырга;

11) 24 нче кушымтада:

а) икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ташлы Кавал авыл җирлеге Бөреле, Каенлык, Мүлмә, Усад авыл җирлекләре, Арча һәм Әтнә муниципаль районнары белән чиктәш.»;

б) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ташлы Кавал авыл җирлеге чиге Каенлык авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Каенлык, Ташлы Кавал авыл җирлекләре һәм Әтнә муниципаль районы чикләре тоташкан урында Олыяз авылыннан 1,0 км көнчыгышта урнашкан 23 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатышка таба 690 м урман полосасының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 550 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Черкаска елгасына кадәр уза, 400 м шушы елга агымы

буенча өскә таба аңа кибеп баручы инеш койган урынга кадәр бара, аннары 1,2 км шушы инеш агымы буенча өскә таба уза, шуннан соң көнбатышка таба 110 м чокыр буйлап бара, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 270 м көнбатышка таба, 500 м көньяк-көнбатышка таба һәм 650 м көньякка таба уза, шуннан соң көньяк-көнбатыш юнәлештә 780 м «Исләйтар урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Ашыт участок урманчылыгындагы 92, 64 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буенча 260 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көнбатышка таба 31 м чокырның көньяк чиге буйлап, Крылай елгасын кисеп үтеп, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 540 м урман полосасының көньяк чиге буйлап һәм 2,4 км урман полосасы буйлап бара, аннары көньякка таба 994 м урман полосасының көнбатыш чиге буйлап, 180 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 300 м көньяк-көнбатышка таба, 330 м көньякка таба бара, аннары көнчыгышка таба 1,3 км урман полосасының көньяк чиге буйлап башка урман полосасы белән кисешкән урынга кадәр бара, шуннан соң уртак юнәлештә көньяк-көнчыгышка таба 1,8 км урман полосасының көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш чикләре буйлап Каенлык, Ташлы Кавал һәм Усад авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Өнсә авылыннан 1,2 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 33 нче тоташу ноктасына кадәр бара.»;

в) бишенче һәм алтынчы абзацларны үз көчләрен югалткан дип танырга;

г) тугызынчы абзацта «Мүлмә, Сосновка» сүзләрен «Бөреле, Мүлмә» сүзләренә алмаштырырга;

д) унынчы абзацта ике урында «Сосновка» сүзен «Бөреле» сүзенә алмаштырырга;

12) 25 нче кушымтада:

а) икенче абзацта «Сосновка,» сүзен төшереп калдырырга;

б) алтынчы абзацта «Сосновка» сүзен «Бөреле» сүзенә алмаштырырга;

в) җиденче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

г) сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Усад авыл җирлеге чиге Бөреле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 35 нче тоташу ноктасыннан алып Крылай елгасы агымы буенча аска таба 240 м уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 670 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 740 м «Шәһәр яны

урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Иске Казан участок урманчылыгындагы 11 нче урман кварталының көнбатыш чиге буйлап, 820 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң уртак юнәлештә көньяк-көнчыгышка таба 460 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 1,8 км шушы урманчылыктагы 13, 169, 16 нчы урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, аннары көньяк-көнбатышка таба 180 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң 360 м Крылай елгасы агымы буенча өскә таба аңа кибеп баручы инеш койган урынга кадәр бара, 1,6 км әлеге инешнең агымы буенча өскә таба уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 70 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 415 м урман полосасының көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары төньяк-көнбатышка таба 1,5 км урман полосасы буйлап, 140 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап «Шәһәр яны урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Иске Казан участок урманчылыгындагы 15 нче урман кварталына кадәр бара, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 850 м әлеге урман кварталының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 1,0 км авыл хуҗалыгы җирләре буйлап шушы урманчылыктагы 17 нче урман кварталына кадәр бара, аннары уртак юнәлештә көньяк-көнчыгышка таба 720 м шушы урман кварталының төньяк чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 750 м төньяк-көнчыгышка таба, 43 м көньяк-көнчыгышка таба, 250 м көньяк-көнбатышка таба, 370 м көньяк-көнчыгышка таба, 150 м көньяк-көнчыгышка таба, аннары шул ук юнәлештә 50 м «Шәһәр яны урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Иске Казан участок урманчылыгындагы 173 нче урман кварталы аерымланган кишәрлекнең көньяк чиге буйлап инешкә кадәр бара, шуннан соң 50 м шушы инеш агымы буенча аска таба башка инеш белән кушылган урынга кадәр бара, көньякка таба 920 м шушы инеш буенча уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 195 м төньяк-көнбатышка таба, 530 м көнбатышка таба, 285 м көньяк-көнчыгышка таба, 160 м көньяк-көнбатышка таба бара, шуннан соң көнчыгышка таба 120 м күмәк бакчаларның төньяк чиге буйлап, аннары уртак юнәлештә көньяк-көнбатышка таба 1,0 км күмәк бакчаларның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, шуннан соң уртак юнәлештә көнбатышка таба 890 м ерганак буйлап бара, аннары көньяк-көнчыгышка таба 650 м урман массивының төньяк-көнчыгыш

чиге буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 350 м шушы урман массивының көньяк-көнчыгыш чиге буйлап һәм уртак юнәлештә көнбатышка таба 1,0 км көньяк чиге буйлап уза, аннары көньяк-көнбатышка таба 195 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап Казансу елгасына кадәр бара, 1,8 км шушы елга агымы буенча өскә таба уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 240 м көньяк-көнбатышка таба һәм 160 м көньяк-көнчыгышка таба Бөреле, Красносельский һәм Усад авыл җирлекләре тоташкан урында Чубар авылыннан 1,3 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 59 нчы тоташу ноктасына кадәр бара.»;

13) 26 нчы кушымтада:

а) икенче абзацта «Сосновка,» сүзен төшереп калдырырга;

б) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Чыпчык авыл җирлеге чиге Бөреле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә Бөреле, Мүлмә һәм Чыпчык авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Ташлы Кавал авылыннан 2,5 км көньяк-көнчыгышта урнашкан 48 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнбатыш юнәлештә 470 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Олы Әтнә – Чыпчык автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,9 км урман массивының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 200 м урман массивы буйлап, 850 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап уза, шуннан соң авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 1,6 км, сынык сызык ясап, көньяк-көнчыгышка таба, 314 м көньякка таба, 960 м, сынык сызык ясап, көньяк-көнбатышка таба кибеп баручы инешкә кадәр бара, 1,1 км шушы инеш агымы буенча аска таба уза, аннары авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 180 м көньяк-көнбатышка таба, 60 м төньяк-көнбатышка таба, 61 м төньяк-көнчыгышка таба бара, шуннан соң уртак юнәлештә төньяк-көнбатышка таба 3,5 км «Шәһәр яны урманчылыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең Иске Казан участок урманчылыгындагы 20, 18 нче урман кварталларының көнчыгыш чиге буйлап уза, аннары уртак юнәлештә көньяк-көнбатышка таба 3,2 км шушы урманчылыктагы 18, 19, 23 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, шуннан соң уртак юнәлештә төньяк-көнбатышка таба 1,4 км шушы урманчылыктагы 22 нче урман кварталының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, аннары уртак юнәлештә көньяк-көнбатышка таба 1,5 км шушы урманчылыктагы 22, 21 нче урман кварталларының төньяк-көнбатыш чиге буйлап бара, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 1,3 км шушы урманчы-

лыктагы 21, 24 нче урман кварталларының көньяк-көнбатыш чиге буйлап Казансу елгасына кадәр уза, 1,6 км шушы елга агымы буенча аска таба бара, аннары Ташлы Кавал – Сосновка – Бөреле станциясе автомобиль юлы буйлап 170 м көньяк-көнбатышка таба, 600 м көньяк-көнчыгышка таба, 540 м көньяк-көнбатышка таба уза, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 170 м күмәк бакчаларның көньяк-көнчыгыш чиге буйлап бара, көньяк-көнчыгышка таба 1,1 км күмәк бакчаларның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап уза, Ташлы Кавал – Сосновка – Бөреле станциясе автомобиль юлын кисеп үтеп, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 280 м урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, аннары көньяк-көнчыгышка таба 100 м бара, Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полосаны кисеп үтеп, шуннан соң көньяк-көнбатышка таба 270 м Горький тимер юлына бүлеп бирелгән полоса буйлап уза, шуннан соң көньяк-көнчыгышка таба 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, Казан – Малмыж автомобиль юлын кисеп үтеп, 1,6 км урман полосасы буенча, 190 м озын чокыр буйлап инешкә кадәр бара, 250 м инеш агымы буенча өскә таба Бөреле, Чыпчык һәм Шәпше авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Тимошкино авылыннан 1,3 км төньяк-көнчыгышта урнашкан 63 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

в) бишенче абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

14) 28 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

15) 29 нчы кушымтада:

а) икенче абзацта «Пермяк» сүзен «Биектау» сүзенә алмаштырырга;

б) дүртенче абзацта «Пермяк» сүзен «Биектау» сүзенә алмаштырырга;

в) бишенче абзацта ике урында «Пермяк» сүзен «Биектау» сүзенә алмаштырырга;

16) 30 нчы кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

**6 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2013 елның 20 мае
№ 42-ТРЗ

Муниципаль берәмлекләр чикләренең тәкъдим ителә торган үзгәрешләр исәпкә алынган

**карта-схемасы**

"Биектау муниципаль районының Биектау һәм Красносельский авыл җирлекләре территорияләре чикләрен үзгәртү, аерым муниципаль берәмлекләрне үзгәртеп кору һәм "Биектау муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" Татарстан Республикасы Законына кушымта




Шартлы билгеләр

- муниципаль берәмлекләрнең чикләре
- Биектау муниципаль районының чиге
А-Б - Биектау авыл җирлегенең һәм Красносельский авыл җирлегенең чиктәш чиге
- җирлекләрнең административ үзәкләре
- торак пунктлар
- Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлегенең Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлеге территориясе составына керә торган территориясе
- Биектау муниципаль районы Биектау авыл җирлегенең Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге территориясе составына керә торган территориясе

# II
# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ҺӘМ АНЫҢ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 774. Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык беренче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының кырык беренче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкиле турында.

2. «2012 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында» 492-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

3. «2012 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында» 493-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

4. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 490-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

5. «Мәгариф турында» 491-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

6. «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 1448-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).

7. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү

хакында» 477-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (III укылыш).

8. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 7.3 һәм 8.1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 467-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында.

9. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 444-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында.

10. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 458-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында.

11. «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 488-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

12. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында (II укылыш).

13. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 475-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).

14. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 485-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).

15. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 494-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

16. «Спас муниципаль районының Иж-Борискино һәм Урта Йорткүл авыл җирлекләрен үзгәртеп кору һәм «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 484-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

17. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 496-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

18. «Татарстан Республикасы Әгерҗе районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участок-

лары чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 487-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

19. Берләшкән Милләтләр Оешмасының коррупциягә каршы 2003 елның 31 октябрендәге конвенциясенең 20 статьясын ратификацияләү турында Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе С.Е. Нарышкинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате хакында.

20. «Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы хакында.

21. «Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Хакасия Республикасы Югары Советының закон чыгару инициативасы хакында.

22. «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык нигезләре турында» 238827-6 номерлы федераль закон проектына төзәтмәләр хакында.

23. «Дару чаралары әйләнеше турында» Федераль законның 52 һәм 55 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

24. Гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре территориаль программасы һәм Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә медицина ярдәме күрсәтү өчен шартлар тудыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен конкретлаштыра торган Россия Федерациясе норматив хокукый актларын әзерләү һәм кабул итү инициативасы белән чыгу турында Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министры В.И. Скворцовага Оренбург өлкәсе Закон чыгару Собраниесе депутатлары мөрәҗәгате хакында.

25. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 14 һәм 16 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 252282-6 номерлы федераль закон проекты турында (төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль хакында).

26. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәреш кертү хакында» 247620-6 номерлы

федераль закон проекты турында (транспортта административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле затлар даирәсен төгәлләштерү өлешендә).

27. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28.4 статьясына үзгәреш кертү хакында» 235431-6 номерлы федераль закон проекты турында (Кодексның 14.13 статьясындагы 1, 2, 4 һәм 5 өлешләре буенча административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле органны төгәлләштерү хакында).

28. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 265219-6 номерлы федераль закон проекты турында (махсус сакланыла торган табигать территорияләрендә табигать ресурсларын саклау һәм алардан файдалану кагыйдәләрен бозган өчен җаваплылыкны көчәйтү хакында).

29. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 257510-6 номерлы федераль закон проекты турында (адвокатка белешмә бирмәгән, белә торып дөрес булмаган белешмә биргән өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә).

30. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 252092-6 номерлы федераль закон проекты турында (башбаштакланып төсле асылташ чималы чыгарган өчен административ җаваплылык билгеләү хакында).

31. «Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 243636-6 номерлы федераль закон проекты хакында (аерым категория транспорт чараларына тикшерү җайланмалары (алкойозаклар) урнаштыру турында).

32. «Россия Федерациясе Җинаять кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Рязань өлкә Думасының закон чыгару инициативасы хакында.

33. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 14.2 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Оренбург өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

34. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7.23 статьясына үзгәреш кертү хакында»

федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Владимир өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.

35. «Ягулык-энергетика комплексы объектлары иминлеге турында» Федераль законның 5 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Әстерхан өлкәсе Думасының закон чыгару инициативасы турында.

36. Россия Федерациясе Наркотиклар әйләнешен тикшереп тору буенча федераль хезмәтенә кеше организмына наркотик яисә психотроп яктан тәэсир итә торган, әмма Россия Федерациясендә тикшерү каралган наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорлары исемлегенә кертелмәгән матдәләр әйләнешен вакытлыча туктатып тору вәкаләтләрен бирү хакында Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Д.А. Медведевка Төньяк Осетия – Алания Республикасы Парламенты мөрәҗәгате турында.

37. Өйдә җитештерелгән куәтле алкогольле эчемлекләрне сатып алган өчен административ җаваплылык билгеләү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларына Белгород өлкә Думасы депутатлары мөрәҗәгате турында.

38. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 67 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 233214-6 номерлы федераль закон проекты турында (күп балалы гаиләләрдән булган балаларның белем алуга хокукларын гамәлгә ашыру өлешендә).

39. «Корал турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Белгород өлкә Думасының закон чыгару инициативасы турында.

40. «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» Россия Федерациясе Законының 4 статьясына һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 13.15 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 259853-6 номерлы федераль закон проекты турында (сексуаль характердагы хезмәт күрсәтүләр турында белдерүләрне массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырганда массакүләм мәгълүмат ирегеннән явыз ниятләрдә файдалануны булдырмау өлешендә).

41. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон-

ның $26^3$ статьясына һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 256495-6 номерлы федераль закон проекты турында (шәһәр яны тимер юл транспортында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өлкәсендә региональ дәүләт контролен Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә кертү турында).

42. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 255972-6 номерлы федераль закон проекты турында (автомобиль юлларының юл буе полосалары чикләрендә зират атрибутикасын урнаштырган һәм куйган өчен җаваплылык билгеләү хакында).

43. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына миграция законнарын бозган очракта, мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза биреп, чит ил гражданнарын мәҗбүри административ җибәрүне билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 247744-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе миграция законнарын бозган чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга карата 120 сәгатьтән алып 200 сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр рәвешендә, алга таба Россия Федерациясе территориясеннән читкә административ җибәрү юлы белән административ җәза куллану турында).

44. Хөкүмәт сәгате: «Бөтендөнья сәүдә оешмасы кагыйдәләре гамәлдә булу шартларында республиканың тотрыклы инновацияле үсешен тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты чаралары турында».

45. Төрлесеннән.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2925-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 775. Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкиле турында

«Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкилләре турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Билалова Диләрә Рөстәм кызын Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясендә җәмәгатьчелек вәкиле итеп билгеләп куярга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2926-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 776. «2012 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында» 492-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кертелгән «2012 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында» 492-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2927-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 777. «2012 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы законы хакында (492-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «2012 елгы Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы законын (492-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2928-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 778. «2012 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында» 493-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кертелгән «2012 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында» 493-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2929-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 779. «2012 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы законы хакында (493-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «2012 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы законын (493-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2930-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 780. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 490-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 490-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2931-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 781. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (490-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (490-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2932-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 782. «Мәгариф турында» 491-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты тарафыннан кертелгән «Мәгариф турында» 491-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитетына 2013 елның 10 июненә кадәр кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты күрсәтелгән закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2013 елның 20 июненә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2933-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 783. Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы хакында (1448-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексын (1448-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән кодексны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2934-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 784. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы хакында (477-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (477-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2935-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 785. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 7.3 һәм 8.1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 467-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 104 статьясындагы 6 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2013 елның 28 мартында беренче укылышта кабул ителгән «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 7.3 һәм 8.1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 467-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын, «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 477-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты белән берләштерүгә бәйле рәвештә, караудан төшереп калдырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2936-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 786. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 444-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 104 статьясындагы 6 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2013 елның 27 апрелендә икенче укылышта кабул ителгән «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 444-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын, «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 477-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты белән берләштерүгә бәйле рәвештә, караудан төшереп калдырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2937-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 787. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 458-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының 104 статьясындагы 6 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2013 елның 27 апрелендә икенче укылышта кабул ителгән «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 458-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын, «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 477-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты белән берләштерүгә бәйле рәвештә, караудан төшереп калдырырга.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2938-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 788. «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 488-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 488-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2939-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 789. «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (488-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (488-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2940-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 790. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына (Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2010 елның 9 июнендәге 973-IV ДС номерлы карары редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 2 (I өлеш); 2005, № 3 (II өлеш), № 10 (II өлеш), № 12 (V өлеш); 2006, № 1, № 10 (I өлеш); 2007, № 10, № 12 (IV өлеш); 2008, № 11 (IV өлеш); 2010, № 6 (III өлеш); 2011, № 3, № 12) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 16 статьяның 2 өлешендә «утырышларында» сүзен төшереп калдырырга;

2) түбәндәге эчтәлекле $16^1$ статья өстәргә:

**«$16^1$ статья**

1. Кичекмәстән хәл ителергә тиешле аерым очракларда Дәүләт Советы Президиумы карарлары Дәүләт Советы Президиумы әгъзаларын сораштыру юлы белән кабул ителергә мөмкин. Дәүләт Советы Президиумының норматив хокукый характердагы карарлары, шулай ук Дәүләт Советы утырышын чакыру, мәсьәләне Дәүләт Советы утырышы көн тәртибенә кертү турында карарлар сораштыру юлы белән кабул ителә алмый.

2. Дәүләт Советы Президиумы әгъзаларын сораштыру Дәүләт Советы Аппаратының Оештыру идарәсе тарафыннан сораштыру кәгазенә Дәүләт Советы Президиумы әгъзаларының шәхси имзаларын җыю юлы белән Дәүләт Советы Рәисенең язмача йөкләмәсе буенча башкарыла. Сораштыру кәгазенең бердәй рәвеше Дәүләт Советы Рәисе тарафыннан раслана.

3. Сораштыру үткәрү һәм сораштыру юлы белән карауга кертелә торган карар проекты турында Дәүләт Советы Президиумының һәрбер әгъзасына хәбәр ителергә тиеш. Дәүләт Советы Президиумының билгеләнгән санлы составының кимендә өчтән икесе сораштыруда катнашса, ул үткәрелгән дип санала.

4. Сораштыру юлы белән кабул ителгән һәм Дәүләт Советы Рәисе тарафыннан имзаланган карар һәм сораштыру кәгазе Дәүләт Советы Президиумының якындагы утырышы беркетмәсенә беркетелә. Шул ук утырышта Дәүләт Советы Президиумы утырышына рәислек итүче сораштыру юлы белән кабул ителгән Дәүләт Советы Президиумы карары, аның нәтиҗәләре хакында Дәүләт Советы Президиумы әгъзаларына мәгълүмат бирә. Мәгълүмат игътибарга алына, бу хакта беркетмәгә языла.»;

3) 22 статьяның 2 өлешенә «, әгәр федераль законнарда башкасы билгеләнмәгән булса.» сүзләрен өстәргә;

4) 35 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Дәүләт Советы үзенең вәкаләтләр чорына депутатлар арасыннан Керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тапшыра торган белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору комиссиясен, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты этикасы кагыйдәләрен үтәү буенча комиссияне, Татарстан Республикасы законнарының татар һәм рус

телләрендәге текстлары тәңгәллеген билгеләү комиссиясен булдыра.»;

б) түбәндәге эчтәлекле 3[1] өлеш өстәргә:

«3[1]. Керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тапшыра торган белешмәләрнең дөреслеген тикшереп тору комиссиясе керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары тапшыра торган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын, депутатларның федераль законнарда, Татарстан Республикасы Конституциясендә һәм «Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны үтәвен тикшереп тора.»;

5) 45 статьяның 1 өлешендә «чыгыш ясау өчен язылучылар исемлеге һәм кергән материаллар турында аларның үтенече белән» сүзләрен «кергән материаллар турында; Дәүләт Советы утырышы барышында Дәүләт Советы депутатлары тапшырган язмача мәгълүматны Дәүләт Советы Секретаре белән килештереп, күбәйтергә һәм таратырга йөкләмә бирә» сүзләренә алмаштырырга;

6) 84 статьяда:

а) 1 өлештә:

беренче абзацта «тапшырылырга» сүзеннән соң «кәгазьдә йә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының Бердәй ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасы ярдәмендә электрон рәвештә» сүзләрен өстәргә;

1 пунктта «, шул исәптән санлы саклагычта,» сүзләрен төшереп калдырырга;

7 пунктта «Татарстан Республикасы бюджеты» сүзләреннән соң «һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты» сүзләрен өстәргә;

б) 5 өлештә «карта-план» сүзен «карта (план), шул исәптән электрон рәвештә,» сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 6 өлеш өстәргә:

«6. Закон проекты тексты һәм әлеге статьяның 1 өлешендәге 2 – 5 пунктларында каралган материаллар белән бер үк вакытта аларның MS Word форматында һәм (яисә)

редакцияләү мөмкин булган башка форматларда электрон рәвештәге күчермәләре тапшырылырга тиеш.»;

7) 87 статьяга түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:

«5. «Татарстан Республикасы Хисап палатасы турында» Татарстан Республикасы Законында каралган закон проектлары бәяләмә өчен әлеге статьяның 1 өлеше нигезендә шулай ук Татарстан Республикасы Хисап палатасына да җибәрелә.»;

8) 88 статьяның 2 өлешендә «үз көчләрен югалткан» сүзләрен «гамәлдә түгел» сүзләренә алмаштырырга;

9) 90 статьяда:

а) 2 өлешнең беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Җаваплы комитет закон проектын Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына, бәяләмә өчен Татарстан Республикасы прокуратурасына, федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган очракларда, – шулай ук әлеге законнарда каралган органнарга һәм оешмаларга да җибәрә.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

«$2^1$. Дәүләт Советы депутатлары, Дәүләт Советы Президиумы яисә комитетлары тарафыннан кертелгән закон проектына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру мөмкинлеген тәэмин итү максатларында күрсәтелгән закон проекты, тиешле бәяләмәләр кабул ителә башлау һәм тәмамлау даталары күрсәтелеп, җаваплы комитетның йөкләмәсе буенча һәм аның тикшереп торуы белән Дәүләт Советы Аппараты тарафыннан Дәүләт Советының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге www.gossov.tatarstan.ru рәсми сайтына урнаштырыла.»;

в) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Закон проекты буенча фикер алышу барышында кергән искәрмәләр һәм тәкъдимнәр җаваплы комитет утырышларында карала. Җаваплы комитет, коррупциягә каршы бәйсез экспертиза бәяләмәләре белән килешмәгән очракта, бәйсез экспертларга 30 көн эчендә дәлилләнгән җавап җибәрә, моңа ачыкланган коррупциячел факторларны бетерү ысуллары турында бәяләмәдә тәкъдим ителмәгән очраклар керми.»;

10) 92 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Закон проектын алдан карау нәтиҗәләре буенча җаваплы комитет түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) закон проектын хупларга һәм Дәүләт Советына закон проектын беренче укылышта кабул итүне тәкъдим итәргә;

2) закон проектын хупларга һәм Дәүләт Советына закон проектын беренче һәм өченче укылышларда кабул итүне тәкъдим итәргә;

3) Дәүләт Советына закон проектын кире кагуны тәкъдим итәргә.»;

б) 3 өлештә:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) җаваплы комитетның закон проекты буенча тәкъдим ителгән карары нигезендә Дәүләт Советы карары проекты;»;

түбәндәге эчтәлекле 5 – 9 пунктлар өстәргә:

«5) Татарстан Республикасы Конституциясенең 76 статьясындагы 3 өлешендә каралган закон проектлары буенча Татарстан Республикасы Президенты бәяләмәсе;

6) Татарстан Республикасы Хисап палатасы бәяләмәсе (булган очракта);

7) Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы бәяләмәсе (булган очракта);

8) хезмәт өлкәсендәге закон проекты буенча Социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен җайга салу буенча республика өчьяклы комиссиясе карары (булган очракта);

9) коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә (булган очракта).»;

в) 5 өлештә «тәкъдим итүчегә эшләп бетерү өчен җибәрә яисә закон проектын кире кага» сүзләрен «закон проектын эшләүне дәвам итү өчен җаваплы комитетка җибәрә» сүзләренә алмаштырырга;

11) 94 статьяның 1 өлешендә «закон проектын беренче укылышта кабул итү турында» сүзләрен төшереп калдырырга;

12) 96 статьяның 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Дәүләт Советы түбәндәге карарларны кабул итәргә мөмкин:

1) закон проектын коррупциягә каршы экспертизага җибәрү турында;

2) закон проектын иҗтимагый экспертиза уздыру өчен Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына җибәрү турында;

3) закон проектын халык фикер алышуына чыгару турында.»;

13) 97 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«97 статья**

Закон проектын беренче укылышта кабул итү турында Дәүләт Советы карары һәм закон проекты биш көн эчендә Татарстан Республикасы Конституциясенең 76 статьясында күрсәтелгән закон чыгару инициативасы хокукына ия субъектларга җибәрелә.»;

14) 99 статьяның 4 өлешендәге сигезенче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Комитет Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсенең, экспертларның закон проекты буенча кергән бәяләмәләрен һәм тәкъдимнәрен, коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләрен, иҗтимагый экспертиза нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы бәяләмәсен, шулай ук закон проектын халык фикер алышуы нәтиҗәсендә кергән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне карый.»;

15) 100 статьяның 2 өлешендә «кабул ителгәннән соң 10 көннән» сүзләрен «кабул ителгән көннән алып 12 көннән» сүзләренә алмаштырырга;

16) 122 статьяның 1 өлешендә «профильле комитет рәисе» сүзләрен «Рәисе» сүзенә алмаштырырга;

17) 17 бүлек исемендә «Татарстан Республикасы Президентына вәкаләтләр бирү» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президентының вазыйфага керешүе» сүзләренә алмаштырырга;

18) 124 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«124 статья**

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 18 статьясы һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 93 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Президенты Дәүләт Советы утырышында тантана барышында ант иткән вакыттан вазыйфага керешә.»;

19) 125 статьяның 1 һәм 2 өлешләрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Президенты вазыйфага керешкәндә ант итү Татарстан Республикасы Конституциясенең

93 статьясы, әлеге Регламент һәм Дәүләт Советы карары белән расланган тәртип нигезендә үткәрелә.

2. Татарстан Республикасы Президенты вазыйфага керешү тантанасы үткәрелә торган Дәүләт Советы утырышы (алга таба әлеге статьяда – Дәүләт Советы утырышы) датасы, Татарстан Республикасының гамәлдәге Президенты һәм Татарстан Республикасының яңа сайланган Президенты фикерләрен искә алып, Дәүләт Советы Президиумы тарафыннан билгеләнә.»;

20) 23 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23 бүлек. **Федерация Советы әгъзасына – Дәүләт Советыннан вәкилгә вәкаләтләр бирү**

**150 статья**

Дәүләт Советы «Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советын формалаштыру тәртибе турында» Федераль закон нигезендә Федерация Советы әгъзасына – Дәүләт Советыннан вәкилгә вәкаләтләр бирә.

**151 статья**

Федерация Советы әгъзасы – Дәүләт Советыннан вәкил вәкаләтләре бирү өчен кандидатуралар карауга Дәүләт Советы Рәисе, фракция яисә депутатларның гомуми саныннан кимендә биштән берен тәшкил итә торган депутатлар төркеме тарафыннан кертелә. Дәүләт Советы Рәисе, фракция, депутатлар төркеме Федерация Советы әгъзасы вәкаләтләре бирү өчен Дәүләт Советы каравына бер генә кандидатура кертү хокукына ия.

**152 статья**

1. Федерация Советы әгъзасы – Дәүләт Советыннан вәкил вәкаләтләре бирү өчен кандидат Дәүләт Советына түбәндәгеләрне тапшырырга тиеш:

1) Федерация Советы әгъзасы вәкаләтләре бирелергә мөмкин булган елга кадәрге ел өчен үзенең керемнәре, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре күләме һәм чыганаклары турындагы белешмәләр;

2) үзенең, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының милекчелек хокукындагы мөлкәте турында белешмәләр;

3) Федерация Советы әгъзасы вәкаләтләре бирелгән очракта Федерация Советы әгъзасы статусына туры килми торган башка эшчәнлеген туктату йөкләмәсе белән гариза;

4) үзенең, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының Россия Федерациясе территориясеннән читтә булган күчемсез милке турында, күрсәтелгән милек сатып алынган акчаларның чыганагы хакында белешмәләр, шулай ук Россия Федерациясе территориясеннән читтә үзенең мөлкәти характердагы йөкләмәләре, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының шундый йөкләмәләре турында белешмәләр;

5) соңгы өч елда җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, акцияләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталында катнашу өлешләре, пайлар) сатып алу буенча алыш-биреш бәясе кандидатның һәм аның хатынының (иренең) алыш-биреш итүгә кадәрге өч ел өчен уртак керемнәреннән артыграк булса, һәр алыш-биреш буенча үзенең чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында һәм алыш-биреш үткәрелгән акчаларны алу чыганаклары хакында белешмәләр;

6) Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлары (кертемнәре) булмау, аларда саклана торган акчалары һәм кыйммәтле әйберләре булмау, чит илләрнең финанс документлары булмау һәм (яисә) аларны кулланмау турында язмача хәбәрнамә.

2. Федерация Советы әгъзасы – Дәүләт Советыннан вәкил вәкаләтләре бирү турындагы мәсьәлә алдан профильле комитет утырышында карала.

**153 статья**

1. Федерация Советы әгъзасы – Дәүләт Советыннан вәкил вәкаләтләре бирү өчен кандидатлар Дәүләт Советы утырышында чыгыш ясыйлар һәм депутатлар сорауларына җавап бирәләр. Һәр депутат яисә депутат берләшмәсе кандидатны хуплап яисә каршы фикер әйтергә хокуклы.

2. Тавыш бирү, үз кандидатураларын кире алганнардан тыш, тәкъдим ителгән кандидатураларның барысы буенча да уздырыла. Үз кандидатурасын кире алу тавыш бирмичә генә кабул ителә.

3. Федерация Советы әгъзасы – Дәүләт Советыннан вәкил вәкаләтләре бирү турында карар депутатларның гомуми саныннан күпчелек тавыш белән кабул ителә һәм Дәүләт Советы карары белән рәсмиләштерелә.

**154 статья**

Федерация Советы әгъзасына – Дәүләт Советыннан вәкилгә вәкаләтләр бирү турында карар үз көченә кергән көннән соң икенче көннән дә соңга калмыйча Дәүләт Советы тарафыннан Федерация Советына җибәрелә һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Дәүләт Советының рәсми сайтына урнаштырыла.

**155 статья**

1. Федерация Советы әгъзасына – Дәүләт Советыннан вәкилгә вәкаләтләр бирү турында карар яңа чакырылыш Дәүләт Советының тулы хокуклы составында беренче утырыш булган көннән алып бер ай дәвамында, шул исәптән алдагы чакырылыш Дәүләт Советы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, кабул ителергә тиеш.

2. Федерация Советы әгъзасы – Татарстан Республикасы вәкиле вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган очракта, Федерация Советының яңа әгъзасына – Дәүләт Советыннан вәкилгә вәкаләтләр бирү турындагы карар Федерация Советының элеккеге әгъзасы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.»;

21) 27 бүлекнең исемендә «Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары» сүзләреннән соң «отставкадагы судьяларны Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары вазыйфаларын башкаруга җәлеп итү» сүзләрен өстәргә;

22) түбәндәге эчтәлекле $165^1$ статья өстәргә:

**«$165^1$ статья**

1. Отставкадагы судьяны Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкаруга җәлеп итү Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе күрсәтмәсе буенча Дәүләт Советы карары нигезендә башкарыла.

2. Отставкадагы судьяны Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкаруга җәлеп итү турындагы мәсьәләне алдан карау Дәүләт Советының профильле комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Отставкадагы судьяны Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкаруга җәлеп итү турындагы карар сайланган депутатлар санының күпчелеге белән ка-

бул ителә һәм өстәмә тавыш бирүдән башка гына Дәүләт Советы карары белән рәсмиләштерелә.»;

23) түбәндәге эчтәлекле $32^2$ бүлек өстәргә:

$32^2$ бүлек. **Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министрының еллык хисапларын карау**

**$190^3$ статья**

1. Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министры полиция эшчәнлеге турында елга бер тапкыр – октябрьдә Дәүләт Советына хисап (алга таба – Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министрының еллык хисабы) тәкъдим итә.

2. Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министрының еллык хисабын тәкъдим итү датасы һәм вакыты, Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министры белән килешеп, Дәүләт Советы Президиумы тарафыннан билгеләнә.

**$190^4$ статья**

Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министрының еллык хисабын тәкъдим итү датасы билгеләнгән көнгә кадәр 14 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы Дәүләт Советына мәгълүматианалитик язма җибәрә, әлеге язмада хезмәт күрсәтелә торган территориядә җәмәгать тәртибен саклау һәм иминлекне тәэмин итү, җинаятьчел каныгулардан гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау буенча үткәрелгән эш, шулай ук халык ышанычын һәм гражданнарга ярдәм итүне тәэмин итү чараларын күрү чагылдырыла.

**$190^5$ статья**

1. Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министрының доклад (чыгыш ясау) рәвешендәге еллык хисабын уздырганда Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министры урынбасары – полиция башлыгы катнаша.

2. Дәүләт Советы белән килешеп, Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министрының еллык хисабын тәкъдим итү вәкаләтләре Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министры тарафыннан Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министры урынбасарына – полиция башлыгына тапшырылырга мөмкин.

3. Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министрының еллык хисабын караганда депутатлар докладчыга со-

раулар бирергә һәм полиция эшчәнлеге турында үзләренең фикерләрен әйтергә хокуклы. Хисап турында фикер алышу өчен вакыт озынлыгы, хисап турында фикер алышуның тәртибе Дәүләт Советы тарафыннан билгеләнә.

4. Татарстан Республикасы буенча эчке эшләр министрының еллык хисабын карау йомгаклары буенча Дәүләт Советы мәгълүматны игътибарга алу турында карар кабул итә, аны Дәүләт Советының профильле комитеты әзерли.»;

24) 191 статьяда:

а) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Президентын сайлаулар датасын билгеләү турында;»;

б) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

«$2^1$. Татарстан Республикасы Президентын чакыртып алу буенча тавыш бирүләрне билгеләү турында;»;

в) түбәндәге эчтәлекле $16^1$ пункт өстәргә:

«16) отставкадагы судьяларны Татарстан Республикасы җәмәгать судьясы вазыйфаларын башкаруга җәлеп итү турында;».

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2941-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 791. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 475-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 475-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2942-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 792. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы законы хакында (475-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы законын (475-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2943-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 793. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 485-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

«Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 485-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын икенче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2944-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 794. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (485-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (485-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2945-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 795. «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 494-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты В.Н. Липужина тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 494-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2013 елның 30 июненә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Дәүләт корылышы һәм җирле үзидарә комитеты күрсәтелгән закон про-

ектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2013 елның 30 июленә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2946-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 796. «Спас муниципаль районының Иж-Борискино һәм Урта Йорткүл авыл җирлекләрен үзгәртеп кору һәм «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 484-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Советы тарафыннан кертелгән «Спас муниципаль районының Иж-Борискино һәм Урта Йорткүл авыл җирлекләрен үзгәртеп кору һәм «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 484-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2947-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 797. «Спас муниципаль районының Иж-Борискино һәм Урта Йорткүл авыл җирлекләрен үзгәртеп кору һәм «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы турында (484-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Спас муниципаль районының Иж-Борискино һәм Урта Йорткүл авыл җирлекләрен үзгәртеп кору һәм «Спас муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын (484-4 номерлы проект) кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2948-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 798. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 496-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Ш.Ш. Яһудин тарафыннан кертелгән «Татарстан

Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 496-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2949-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 799. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы хакында (496-4 номерлы проект)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын (496-4 номерлы проект) кабул итәргә.
2. Күрсәтелгән законны Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2950-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 800. «Татарстан Республикасы Әгерҗе районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 487-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында» 487-4 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

2. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләр 2013 елның 15 июненә кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына кертелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты күрсәтелгән закон проектын, кергән төзәтмәләрне исәпкә алып, 2013 елның 25 июненә кадәр эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына икенче укылышта карауга кертергә тиеш

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2951-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 801. Берләшкән Милләтләр Оешмасының коррупциягә каршы 2003 елның 31 октябрендәге конвенциясенең 20 статьясын ратификацияләү турында Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе С.Е. Нарышкинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Берләшкән Милләтләр Оешмасының коррупциягә каршы 2003 елның 31 октябрендәге конвенциясенең 20 статьясын ратификацияләү турында Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе С.Е. Нарышкинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате текстын кабул итәргә.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы Рәисе С.Е. Нарышкинга җибәрергә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының әлеге мөрәҗәгатен хуплау тәкъдиме белән Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарына мөрәҗәгать итәргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2952-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 802. «Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2953-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 803. «Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Хакасия Республикасы Югары Советының закон чыгару инициативасы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясына үзгәреш кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Хакасия Республикасы Югары Советының закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Хакасия Республикасы Югары Советына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2954-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 804. «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык нигезләре турында» 238827-6 номерлы федераль закон проектына төзәтмәләр хакында

Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы тарафыннан беренче укылышта кабул ителгән «Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык нигезләре турында» 238827-6 номерлы федераль закон проектын карап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Күрсәтелгән закон проектына төзәтмәләрне кабул итәргә һәм аларны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасының Милек мәсьәләләре комитетына кертергә.
2. Әлеге карарны, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары керткән төзәтмәләрне хуплауны сорап, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарына җибәрергә.
3. Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында әлеге закон проектына төзәтмәләрне караганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советын тәкъдим итүне Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты Ильясов Радик Сабит улына йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2955-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 805. «Дару чаралары әйләнеше турында» Федераль законның 52 һәм 55 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Дару чаралары әйләнеше турында» Федераль законның 52 һәм 55 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Карелия Республикасы Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2956-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 806. Гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре территориаль программасы һәм Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә медицина ярдәме күрсәтү өчен шартлар тудыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен конкретлаштыра торган Россия Федерациясе норматив хокукый актларын әзерләү һәм кабул итү инициативасы белән чыгу турында Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министры В.И. Скворцовага Оренбург өлкәсе Закон чыгару Собраниесе депутатлары мөрәҗәгате хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре территориаль программасы һәм Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә медицина ярдәме күрсәтү өчен шартлар тудыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен конкретлаштыра торган Россия Федерациясе норматив хокукый актларын әзерләү һәм кабул итү инициативасы белән чыгу турында Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министры В.И. Скворцовага Оренбург өлкәсе Закон чыгару Собраниесе депутатлары мөрәҗәгатен хупларга.

2. Әлеге карарны Оренбург өлкәсе Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2957-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 807. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 14 һәм 16 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 252282-6 номерлы федераль закон проекты турында (төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 14 һәм 16 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 252282-6 номерлы федераль закон проектын (төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2958-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 808. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәреш кертү хакында» 247620-6 номерлы федераль закон проекты турында (транспортта административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле затлар даирәсен төгәлләштерү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәреш кертү хакында» 247620-6 номерлы федераль закон проектын (транспортта административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле затлар даирәсен төгәлләштерү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2959-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 809. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28.4 статьясына үзгәреш кертү хакында» 235431-6 номерлы федераль закон проекты турында (Кодексның 14.13 статьясындагы 1, 2, 4 һәм 5 өлешләре буенча административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле органны төгәлләштерү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 28.4 статьясына үзгәреш кертү хакында» 235431-6 номерлы федераль закон проектын (Кодексның 14.13 статьясындагы 1, 2, 4 һәм 5 өлешләре буенча административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле органны төгәлләштерү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2960-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 810. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 265219-6 номерлы федераль закон проекты турында (махсус саклана торган табигать территорияләрендә табигать ресурсларын саклау һәм алардан файдалану кагыйдәләрен бозган өчен җаваплылыкны көчәйтү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 265219-6 номерлы федераль закон проектын (махсус саклана торган табигать территорияләрендә табигать ресурсларын саклау һәм алардан файдалану кагыйдәләрен бозган өчен җаваплылыкны көчәйтү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2961-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 811. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 257510-6 номерлы федераль закон проекты турында (адвокатка белешмә бирмәгән, белә торып дөрес булмаган белешмә биргән өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 257510-6 номерлы федераль закон проектын (адвокатка белешмә бирмәгән, белә торып дөрес булмаган белешмә биргән өчен административ җаваплылык билгеләү өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2962-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 812. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 252092-6 номерлы федераль закон проекты турында (башбаштакланып төсле асылташ чималы чыгарган өчен административ җаваплылык билгеләү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 252092-6 номерлы федераль закон проектын (башбаштакланып төсле асылташ чималы чыгарган өчен административ җаваплылык билгеләү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2963-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 813. «Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 243636-6 номерлы федераль закон проекты хакында (аерым категория транспорт чараларына тикшерү җайланмалары (алкойозаклар) урнаштыру турында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 243636-6 номерлы федераль закон проектын (аерым категория транспорт чараларына тикшерү җайланмалары (алкойозаклар) урнаштыру турында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2964-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 814. «Россия Федерациясе Җинаять кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Рязань өлкә Думасының закон чыгару инициативасы хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе Җинаять кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Рязань өлкә Думасының закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Рязань өлкә Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2965-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 815. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 14.2 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Оренбург өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 14.2 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Оренбург өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Оренбург өлкәсе Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2966-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 816. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7.23 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Владимир өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 7.23 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Владимир өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Владимир өлкәсе Закон чыгару Собраниесенә җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2967-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 817. «Ягулык-энергетика комплексы объектлары иминлеге турында» Федераль законның 5 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Әстерхан өлкәсе Думасының закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Ягулык-энергетика комплексы объектлары иминлеге турында» Федераль законның 5 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Әстерхан өлкә Думасының закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Әстерхан өлкәсе Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2968-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 818. Россия Федерациясе Наркотиклар әйләнешен тикшереп тору буенча федераль хезмәтенә кеше организмына наркотик яисә психотроп яктан тәэсир итә торган, әмма Россия Федерациясендә тикшерү каралган наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорлары исемлегенә кертелмәгән матдәләр әйләнешен вакытлыча туктатып тору вәкаләтләрен бирү хакында Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Д.А. Медведевка Төньяк Осетия – Алания Республикасы Парламенты мөрәҗәгате турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Россия Федерациясе Наркотиклар әйләнешен тикшереп тору буенча федераль хезмәтенә кеше организмына наркотик яисә психотроп яктан тәэсир итә торган, әмма Россия Федерациясендә тикшерү каралган наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорлары исемлегенә кертелмәгән матдәләр әйләнешен вакытлыча туктатып тору вәкаләтләрен бирү хакында Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе Д.А. Медведевка Төньяк Осетия – Алания Республикасы Парламенты мөрәҗәгатен хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Төньяк Осетия – Алания Республикасы Парламентына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2969-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 819. Өйдә җитештерелгән куәтле алкогольле эчемлекләрне сатып алган өчен административ җаваплылык билгеләү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларына Белгород өлкә Думасы депутатлары мөрәҗәгате турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. Өйдә җитештерелгән куәтле алкогольле эчемлекләрне сатып алган өчен административ җаваплылык билгеләү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларына Белгород өлкә Думасы депутатлары мөрәҗәгатен хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Белгород өлкә Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2970-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 820. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 67 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 233214-6 номерлы федераль закон проекты турында (күп балалы гаиләләрдән булган балаларның белем алуга хокукларын гамәлгә ашыру өлешендә)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 67 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 233214-6 номерлы федераль закон проектын (күп балалы гаиләләрдән булган балаларның белем алуга хокукларын гамәлгә ашыру өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2971-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 821. «Корал турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Белгород өлкә Думасының закон чыгару инициативасы турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Корал турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәреш кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Белгород өлкә Думасының закон чыгару инициативасын хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына һәм Белгород өлкә Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2972-IV ДС

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**822. «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» Россия Федерациясе Законының 4 статьясына һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 13.15 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 259853-6 номерлы федераль закон проекты турында (сексуаль характердагы хезмәт күрсәтүләр турында белдерүләрне массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырганда массакүләм мәгълүмат ирегеннән явыз ниятләрдә файдалануны булдырмау өлешендә)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» Россия Федерациясе Законының 4 статьясына һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 13.15 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 259853-6 номерлы федераль закон проектын (сексуаль характердагы хезмәт күрсәтүләр турында белдерүләрне массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырганда массакүләм мәгълүмат ирегеннән явыз ниятләрдә файдалануны булдырмау өлешендә) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2973-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
## ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

### 823. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның $26^3$ статьясына һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 256495-6 номерлы федераль закон проекты хакында (шәһәр яны тимер юл транспортында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өлкәсендә региональ дәүләт контролен Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә кертү турында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның $26^3$ статьясына һәм Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 256495-6 номерлы федераль закон проектын (шәһәр яны тимер юл транспортында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өлкәсендә региональ дәүләт контролен Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә кертү турында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2974-IV ДС

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

## 824. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 255972-6 номерлы федераль закон проекты турында (автомобиль юлларының юл буе полосалары чикләрендә зират атрибутикасын урнаштырган һәм куйган өчен җаваплылык билгеләү хакында)

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 255972-6 номерлы федераль закон проектын (автомобиль юлларының юл буе полосалары чикләрендә зират атрибутикасын урнаштырган һәм куйган өчен җаваплылык билгеләү хакында) хупларга.

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына җибәрергә.

**Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин**

Казан шәһәре,
2013 елның 30 мае
№ 2975-IV ДС

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**825. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына миграция законнарын бозган очракта, мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза биреп, чит ил гражданнарын мәҗбүри административ җибәрүне билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 247744-6 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе миграция законнарын бозган чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга карата 120 сәгатьтән алып 200 сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр рәвешендә, алга таба Россия Федерациясе территориясеннән читкә административ җибәрү юлы белән административ җәза куллану турында)**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы **карар бирә**:

1. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына миграция законнарын бозган очракта, мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза биреп, чит ил гражданнарын мәҗбүри административ җибәрүне билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү хакында» 247744-6 номерлы федераль закон проектын (Россия Федерациясе миграция законнарын бозган чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга карата 120 сәгатьтән алып 200 сәгатькә кадәр мәҗбүри эшләр рәвешендә, алга таба Россия Федерациясе территориясеннән читкә административ җибәрү юлы белән административ җәза куллану турында) хупларга.

